**МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ**
**«УПРАВЛЕНИЕ ОБРАЗОВАНИЯ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА**
**ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»**

**МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ**
**ДОШКОЛЬНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ**
**«ДЕТСКИЙ САД №3 «КОЯШКАЙ»ЧИСТОПОЛЬСКОГО**
**МУНИЦПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

# «Реализация этнокультурного компонента в дошкольной образовательной организации» (из опыта работы ДОУ г. Чистополя)



***Сборник материалов***
***муниципального семинара-практикума***
***среди педагогов дошкольных образовательных учреждений***
***29 марта 2025 года***

***в рамках деятельности базового детского сада с***
***воспитанием и обучением на татарском языке***

**г. Чистополь – 2025 г.**

**МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ**
**«УПРАВЛЕНИЕ ОБРАЗОВАНИЯ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»**

**МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ДОШКОЛЬНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ДЕТСКИЙ САД №3 «КОЯШКАЙ»ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

# «Реализация этнокультурного компонента в дошкольной образовательной организации» (из опыта работы ДОУ г. Чистополя)

***Сборник материалов муниципального семинара-практикума среди педагогов дошкольных образовательных учреждений 29 марта 2025 года***

***в рамках деятельности базового детского сада с воспитанием и обучением на татарском языке***

***г. Чистополь – 2025 г.***

Рекомендовано к печати МКУ «Управление образования Исполнительного комитета Чистопольскогомуниципального района Республики Татарстан»

**Редакционная комиссия:**
методист по дошкольному воспитанию МКУ «Управление образования Исполнительного комитета Чистопольского муниципального района Республики Татарстан» О.В. Маслакова, заведующий МБДОУ «Детский сад №3 «Кояшкай» Чистопольского муниципального районаРеспублики Татарстан Г.И. Салахеева

**Составитель и технический редактор:**
Старший воспитатель МБДОУ «Детский сад №3«Кояшкай»
Л.В. Исмагилова

**Реализация этнокультурного компонента в дошкольной образовательной организации.** Сборник материалов муниципального семинара- практикума среди педагогов дошкольных образовательных учреждений– МБДОУ
«Детский сад №3 «Кояшкай»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан, 2022– 75 с.

В данном методическом сборнике представлены материалы по планированию и прогнозированию работы по реализации этнокультурного компонента в ДОУ, опыт лучших дошкольных организаций по созданию краеведческих уголков, центров и музеев, авторские игры педагогов ДОУ по обучению детей татарскому(родному) языку. Сборник адресован педагогам дошкольных образовательных учреждений и может быть использованы в теории и практике работы детских садов.

**СОДЕРЖАНИЕ**

1. Балалар бакчасының этномәдәни киңлегендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларның коммуникатив компетентлылыгын үстерү. Л.В. Исмагилова ........................................5
2. Әкиятләр аша мәктәпкәчә яшьтәге балаларның этномәдәни компетентлыгын формалаштыру, этнотолерантлык тәрбияләү.Р.М.Сибгатуллина.................................8
3. Зурлар төркеме өчен «Гөлназның читекләре» шөгыле. Р.Р. Габитова… ................11
4. Этнокультур компетентлыкны балалар бакчасыннан башлап тәрбияләү. Г.Н.Вафина ........................................................................................................15
5. Фольклор - мәктәпкәчә яшьтәге балаларның этномәдәни компетентлыгын үстерү нигезе. А.Ш.Мингулова. .............................................................................. 17
6. Мәктәпкә әзерлек төркеме өчен «Иделчеләр-сәяхәтчеләр» шөгыле. Ю.Т.Хаматгалимова.......................................................................................... 19
7. Интеграция деятельности воспитателя по обучению татарскому языку и музыкального руководителя в процессе приобщения дошкольников к народной культуре. Г.Г. Ахметова, А.А. Астафьева ..................................................22
8. Приобщение детей младшего дошкольного возраста к истокам национальной культуры через использование фольклора. Г.Г. Камалова, Е.В. Багманова...............26
9. Тарихтан башка киләчәк юк. Г.А. Галяутдинова ................................................... 34
10. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның коммуникатив компетенцияләрен формалаштыру өчен заманча мәгълүмати ресурсларны куллану. Г.Г. Гатина, Л.Ш.Мухаметзянова ..............................................................................................36
11. Балаларны татар халкының гореф- гадәтләре, йолалалары, бәйрәмнәре үрнәгендә тәрбияләү. Г.Р. Хуснутдинова ..............................................................39
12. Презентация пособия - лэпбука по этнокультурному компоненту «Народы Татарстана – башкиры, марийцы, мордва, удмурты, чуваши». Л.А.Юнусова, А.Ф. Шайдуллина. ....................................................................................................... 41
13. Квест-игра «Тайны народов Поволжья». А. Р. Булатова, Г.И. Закирова.............45
14. Татар халык сәнгать культурасын өстәмә белем аша киңәйтү. Э.А. Закирова ... 49
15. Балалар бакчасында театр эшчәнлеге аша балаларга милли тәрбия бирү. А.И. Аминова, Д.Ф.Сафина. .......................................................................................51
16. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның этномәдәни белемен формалаштыру буенча « Туган як нәрсәдән башлана?» педагогик проекты. А.И. Нуруллина. ......................54
17. «Использование квест-игр в реализации этнокультурного компонента в работе с дошкольниками». А.А. Сиразетдинова .................................................................. 64
18. Хикмәтле дә, бизәкле дә, әнкәм биргән туган тел! исемле проект. А.М. Гибадуллина.....................................................................................................66
19. Тәрбиячеләр белән берлектә: «Татар хатын-кызларынын милли бизәнү әйбере – брошка» диеп исемләнгән мастер-класс. Г.А. Ахмерова. ......................................... 72
20. Презентация мнемо игры «Найди пару» Л.Г.Мирсайзянова ............................... 75

**Ответственность за точность цитат, имен, названий и иных сведений, а также за соблюдение законов об интеллектуальной собственности несут авторы публикуемых материалов**

**Балалар бакчасының этномәдәни киңлегендә мәктәпкәчә яшьтәге балаларның коммуникатив компетентлыгын үстерү**

Л.В. Исмагилова, старший воспитатель
МБДОУ «Детский сад№3»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

*Төп сүзләр: мәктәпкәчә белем бирү, белем системасы, компетентлылык, коммуникатив компетентлылык, күпмилләтле шәхес, җәмгыять, мәгариф.*

Бүгенге көндә балалар бакчасы, беренче чиратта, белем бирү сыйфатын яхшыртуга юнәлтелгән гаять зур үзгәрешләр кичерә. Әлеге проблеманы хәл итү белем бирү эчтәлеген модернизацияләү, белем бирү процессын оештыру ысулларын һәм технологияләрен оптимальләштерү һәм, әлбәттә, мәктәпкәчә белем бирүнең максатын һәм нәтиҗәләрен яңадан аңлау белән бәйле. Россия мәгариф системасында үзәк төшенчә сыйфатында компетентлылык төшенчәсе ешрак очрый.

Хәзерге иҗтимагый шартларда мәктәпкәчә белем бирү алдында тәрбияләнүчеләрне белем системасы белән коралландыру гына түгел, бәлки стандарт булмаган фикерләргә, куелган бурычларны креатив рәвештә хәл итәргә, нәтиҗәле хезмәттәшлек итәргә, шулай ук мобиль булырга һәм үзгәрә торган тормыш шартларына җиңел җайлашырга сәләтле шәхес формалаштыруны да тәэмин итү бурычы тора.

Компетентлы алым мәктәпкәчә белемне тәмамлаучыда заманча икътисад шартларында, технологияләр алмашынуда, социаль мөнәсәбәтләрнең динамик үсешенә җайлашып, укыту эшчәнлеген уңышлы тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк.

Коммуникатив компетентлылык мәктәпкәчә яшьтә иң мөһим компетентлыкларның берсе булып тора, ул субъектның башка балалар, өлкәннәр белән нәтиҗәле мөнәсәбәтләр корырга әзерлеген билдергән белем бирү нәтиҗәсе, коллективта, җәмгыятьтә уңышлы социальләшү, мәктәпкә яраклашу һәм тормыш шартларына тиз яраклашу өчен кирәкле мөһим тормыш күнекмәләренә ия булу.

Социаль окоммуникатив компетенцияне формалаштыру балаларга әйләнә-тирәдәгеләрнең эмоциональ халәтен аңларга, аралашуда кирәкле мәгълүмат алырга, өлкәннәр һәм яшьтәшләр белән диалог алып барырга, коллектив эшләрдә катнашырга, башка кешене тыңлый белергә, шулай ук талашмаска, конфликтлы ситуацияләрдә үзеңне адекват тотарга мөмкинлек бирә. Әлеге күнекмәләр балалар бакчасының этномәдәни пространствосы шартларында хәзерге заман мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен гаять кирәкле һәм актуаль була бара.

Бу заманча балалар бакчасының күпмилләтле белем бирү оешмасына

әверелүе белән аңлатыла, аның киңлегендә балаларның күпмилләтле шәхесен формалаштыру өчен шартлар тудырыла.

Баланы балалар бакчасының күпмәдәни киңлегендә тәрбияләү педагоглардан югары һөнәри белем дәрәҗәсен үстерүне, дөнья һәм милли мәдәниятләрнең гомумкешелек кыйммәтләре нигезләрен белүне, һөнәри педагогик һәм шәхес сыйфатлары җыелмасын, аларны мәктәпкәчә белем бирү оешмасының күпмәдәни белем бирү киңлегендә реаль белем бирү практикасында куллануның нәтиҗәлелеген таләп итә.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, күптөрле мәдәниятләрнең төп идеясе булып күпләгән төрле мәдәниятләр җәмгыятендә яшәүнең чагылышы тора. Заманча балалар бакчасы чуар милли состав белән характерлана. Милләтара мөнәсәбәтләрне яхшырту, шул исәптән үсеп килүче буында аларның мәдәниятен формалаштыру, толерантлык һәм халыклар дуслыгы идеяләрен раслау мәсьәләләренең барлык күпмилләтле дәүләтләрдә, аерым алганда, илебездә педагогик фән вәкилләренең игътибар үзәгендә торуы бер дә гаҗәп түгел

Күпмилләтле балалар бакчасында педагогик процесс балалар төркеменең күпмәдәни тирәлегенә бәйле. Шул ук вакытта педагогка башка мәдәниятләргә кыйммәт мөнәсәбәтне трансляцияләү генә түгел, эшендә мәдәният чараларын үз эченә алган педагогик технологияләрне, полимәдәни төркем балаларын тәрбияләүнең стандарт булмаган ысулларын да турыдан-туры кулланырга кирәк.

Балаларны үз халкы һәм янәшә яшәүче милләтләре мәдәниятенә чакырып, педагог балаларда үз шәхси индивидуальлеге, мәдәни үзидентификациясе турында күзаллау формалаштыра, шул ук вакытта полимәдәни үзенчәлеге гомумкешелекнең әһәмиятен ассызыклый гына. Тәрбияче мәктәпкәчә яшьтәге балаларның башка милләт балалары белән үзара хезмәттәшлектә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрен ничек җайга салырга кирәклеген белергә тиеш, чөнки нәкъ менә мәктәпкәчә учреждениеләр педагоглары мәдәни традицияләрне ныгытуда, балаларга төрле мәдәниятләр өчен хас булган үз-үзеңне тоту нормаларын һәм кыйммәтләрен тәрбияләүдә зур роль уйный.

Балалар бакчасында белем бирү процессын дөрес оештыру, ышанычлы һәм дустанә атмосфера, әйләнә-тирәдәге балалар - коммуникатив компетентлы балаларны тәрбияләү өчен зарури шарт.

Шулай итеп, мәктәпкәчә яшьтә коммуникатив компетентлыкны үстерү проблемасы социаль әһәмияткә ия, аны хәл итү җәмгыятьнең һәм мәгарифнең көнүзәк мәсьәләләренә кагыла.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Бакланова Т.И. Концепция этнокультурного образования в Российской Федерации
[Текст] / Т.И. Бакланова // Восток и Запад: глобализация и культурная

идентичность. – Казань: Каз.ГУКИ, 2005. – С. 3–13.
2. Бакланова Т.И. Народная художественная культура в универсальной гуманитарной
образовательной системе [Текст] / Т.И. Бакланова // Народная художественная культура России: перспективы развития и подготовки кадров: Материалы международной научно-практической конференции / Науч. ред. Т.И. Бакланова. – М.: МГИК, 1994. – С. 90–94.
3. Бакланова Т.И. О введении в научный оборот и современных определениях понятий
«этнохудожественное образование» и «этнокультурное образование» [Текст] / Т.И. Бакланова // Новое слово в науке: перспективы развития: Материалы VII Междунар.науч.-практ. конф. (Чебоксары, 15 янв. 2016 г.). В 2 т. Т. 1. – Чебоксары: ЦНС «Интерактив плюс», 2016. – №1 (7). – С. 157–160.
4. Бакланова Т.И. Особенности межкультурного образования в России [Текст] / Т.И. Бакланова // Инновационная деятельность в образовании: VII Международная научно-практ. конференция (Москва, 23 апреля 2013 г.): Сб. науч. ст. В 2-х ч. Ч. 2. – М. – Пушкино: НОЧУ ДПО «Институт развития образовательных технологий», 2013. – С. 71–76.
5. Синова И.В. Народы России. История и культура, обычаи и традиции. – СПб.: Издательский Дом «Литера», 2010.
6. Плаксина Е.С. Поликультурное образование детей дошкольного возраста [Текст] /
Е.С. Плаксина // Проблемы и перспективы развития образования: Материалы V междунар. науч. конф. (г. Пермь, март 2014 г.). – Пермь: Меркурий, 2014. – С. 84–85.
7. Иванова А.В. Модели организации непрерывного этнокультурного и поликультурного образования / А.В. Иванова, Н.И. Филиппова // Педагогическое образование в России. –
2016. – №3. – С. 206–212.
8.Портнягина А.В. Развитие этнокультурной компетенции детей посредством взаимодействия кластерной системы «родители – дети – социум» / А.В. Портнягина, Е.И. Сартаева // Народное образование Якутии. – 2016. – №4 (100). – С. 93–94.
9.Гуров В.Н. Ребенок в поликультурной среде: практика работы образовательного учреждения [Текст] / В.Н. Гуров. – Ставрополь: СКИПКРО, 2015. – 175 с.
10. Комратова Н.Г. Дошкольное детство и основы национальной культуры / Н.Г. Комратова // Дошкольное воспитание. – 2008. – №9. – 86 с

**Әкиятләр аша мәктәпкәчә яшьтәге балаларның этномәдәни компетентлыгын формалаштыру, этнотолерантлык тәрбияләү**

Р.М. Сибгатуллина, воспитатель
МБДОУ «Детский сад№3»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

*Төп сүзләр: этнотолерант мөнәсәбәт, халык авыз иҗаты, музыкаль фольклор, халык сәнгате, иҗади проект, Ватан, гореф-гадәтләре.*

Этномәдәни тәрбиянең максаты - балаларны рухи-әхлакый яктан тәрбияләү, үстерү, илебез мәдәнияте кыйммәтләре аша камиллеккә омтылыш уяту.

Балаларны региональ мәдәняткә тарту, милли традицияләргә кызыксыну уяту - бүгенге көннең бик актуаль мәсьәләсе.

Халык аваз иҗаты, музыкаль фольклор, халык сәнгате мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем һәм тәрбия бирүдә чагыла. Ата-бабаларның тарихын һәм мәдәниятен белмәгән халык рухи яктан ярлы була.

Нәкъ менә шуңа күрә, без, традицион халык мәдәнияте нигезләрен, мәдәни киңлекне үзләштерү тәҗрибәсен, аны киләчәк буыннарга тапшыру кирәклеген аңлап эшләргә тырышабыз.

Мин алып бара торган “Әкият сукмаклары буенча” диеп исемләнгән иҗади педагогик проект эшчәнлеге, балаларны туган як тарихы һәм мәдәнияте, баланы әйләндереп алган табигый, социаль һәм иҗат дөньясы белән таныштыруга, тулы бер гармонияле шәхес тәрбияләүгә юнәлдерелгән.

*Проектның максаты:* мәктәпкәчә яшьтәге балаларның этномәдәни компетентлыгын формалаштыру.

*Проектның бурычлары*: балаларда милли төбәк мәдәниятенең төп этномәдәни кыйммәтләрен, рухи-әхлакый сыйфатларны формалаштыру; туган якка, табигатькә, гаиләгә, Ватанга карата мәхәббәт һәм уңай этнотолерант мөнәсәбәт тәрбияләү; поликультуралы белем бирү.

Татарстан республикасы күпмилләтле дәүләт. Идел буенда күп милләт халкы яши. Тәрбияче балаларда һәр милләт кешесенә, һәр милләт халкының гореф-гадәтләренә карата хөрмәт, кызыксыну тәрбияләргә тиеш. Балаларны төрле милләт халкының гореф-гадәтләре, уеннары, милли биюләре, киемнәре, аш-сулары, атаклы кешеләре турында төшендерү төп бурычларның берсе итеп саныйм.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны этномәдәни һәм әхлакый тәрбияләү системасында әкиятләрнең роле бик мөһим, этнотолерантлыкны тәрбияләүдә иң кулай, уңай чараларның берсе. Әкиятләр балаларда мәрхәмәтлелек, түземлелек, игелеклелек, шәфкатьлелек, юмартлык һ.б. шундый сыйфатларны тәрбияләүдә зур роль уйный. Әкиятләр уку, иллюстрацияләрен карау, әңгәмәләр уздыру, әкиятләрне сәхнәләштерү, катнашучы геройлар белән очрашу балаларда уңай тәэсир калдыра.

Без балаларны кече яшьтән, төрле милләт халкының әкиятләре белән таныштырабыз.

Мәс: Мари халкының “Керпе һәм куян” әкияте юкка гына өйрәтмәгән: җитез аяклар белән беренче йөгереп килеп түгел, ә акыл белән уйлап җиңеп булганны күрсәтә.

Удмурт халкының “Боек куян” әкияте: эшләгән ашый, эшләмәгән башын кашый дип хезмәт кешесенең хөрмәткә лаек икәненә төшендерә.

Мордва халкының “Эт үзенә ничек дус тапты?” әкияте кешеләрне тышкы кыяфәтләренә карап хөкем итмәскә өйрәтә.

Үзебезнең милли горурлыкларыбыз янәшәсендә башка күрше милләт халкына караган культура истәлекләрен өйрәнү, балаларның әйләнә-тирәне танып-белүен арттыра, башкаларга ихтирам белән карарга өйрәтә.

“Әкият илендә” дигән үзем ясаган лэпбукка татар халык иҗаты җәүһәрләренең 16 әкиятен тупладым. Шушы әкиятләр буенча 12 уен төзедем. Бу уеннар, әкиятләр миңа зур ярдәмчеләр.

“Зөһрә йолдыз”, “Өч кыз”, “Гөлчәчәк” әкиятләре изге, саф, киң күңелле, ярдәмчел, игътибарлы, мәрхәмәтле татар кызы образы аркылы балаларны да шундый ук булырга өнди.

“Алтын бөртекләр” әкияте түземлелек, тырышлык, сабырлык сыйфатларын алгы планга чыгара.

“Куркак юлдаш” әкияте ышанычлы дус таба белергә, бәла килгәндә ярдәм итәргә, дустыңны авыр хәлдә ташламаска өйрәтә. Һәрбер әкият тәрбияви сыйфатка ия.

Бала әкият геройлары мисалында сак булырга, хәвеф-хәтәрләрне кисәтергә, барлыкка килгән тормыш ситуацияләрендә ориентлашырга өйрәнә. Әкият аша тәрбияләүне борынгы заманнардан ук кулланганнар. Бу мәктәпкәчә педагогикада тәрбия бирүнең иң төп чарасы булып тора. Бала әкият геройларының гамәлләре белән үзен бәяләргә һәм чагыштырырга өйрәнә.

Күп кенә педагоглар әкият баланың сәламәтлегенә һәм психикасына да тәэсир итә, дип саный. Әйтик, әкият ярдәмендә агрессияне киметергә һәм бала белән мөмкин булган күп кенә конфликтлы ситуацияләрдән качарга, шулай ук психосоматик авыруларны кисәтергә мөмкин.

4 яшькә кадәрге балалар хайваннар яки хайваннар катнашындагы әкиятләр тыңлауны өстен күрә. Алар үзләрен хайваннар белән чагыштыралар. Биш яшьтә балалар үзләрен тылсымлы әкият геройлары белән тиңләштерәләр, үзләрен принцессалар, царевичлар һәм царевналар, һ. б. итеп күз алларына китерәләр. Алты яшьтән бала тылсымлы әкиятләргә “күчә”.

Этнотолерантлык тәрбияләү максатыннан тиешле әкиятләр тупланырга тиеш. Иң мөһиме - әкиятләрне дөрес сайлау. Хәер, теләсә нинди әкиятне этнотолерантлык тәрбияләү максатында кулланырга мөмкин, ягъни, яңа әкияттә бала өчен барысы да яңа, һәм ул бу яңалыкны кабул итәргә тиеш.

Әкиятләр белән эшләүне без 1 нче кечкенәләр төркеменнән үк башлыйбыз. Билгеле, бу яшьтә эчтәлеге аңлаешлы, озын булмаган, гади әкиятләрне сайлыйбыз. Бер үк әкиятне төрле вариантларда, кабат - кабат сөйләргә тырышабыз. Мәс: “Шалкан” әкиятен алыйк. Аны өстәл театры ярдәмендә дә, бармак театры итеп тә, фланелеграфта да билгеле бер аралыкта, баланың исендә калырлык итеп кабатлап күрсәтәбез.

Ә инде әкиятнең эчтәлеге баланың исендә калгач, ул үзе үк бу эшне кабатлый башлый, мәс.кечкенә уенчыклар, өстәл театры, курчак театры ярдәмендә. Балалар бигрәк тә бармакка киеп уйнарга, әкиятнең эчтәлеген сөйләргә яраталар.

Бала үскән саен бу эшне катлауландырып әкиятләрне сәхнәләштерү эшенә керешәбез, театрлар куя башлыйбыз. Бусы инде балалар өчен тагы да кызыклы, катлаулы бер дөнья. Алар үзләрен артистлар итеп тоя башлыйлар, бөтен күңелләрен биреп тырышып уйныйлар.

Әкиятне сәхнәләштергән вакытта балада уз-узенә ышаныч арта, бала вакыйгаларның чынлыгына ышана, шатлана яки киресенчә борчыла. Бу нәни баланың эчке активлыгын, аның күңел көчләрен уңай якка юнәлтергә, аң һәм белем эшчәнлеген активлаштырырга ярдәм итә. Ул дөрес интонация белән, төрле хәрәкәтләр, мимикаларны кулланырга, эмоциональ һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнә.

Ягъни бу эшчәнлектә без балаларның иҗади сәләтләрен устерәбез һәм инде явызлыкны, усаллыкны гаепли, ә гаделлекне яклый, барлык кешеләргә карата да гадел, игелекле, мәрхәмәтле булырга өйрәтәбез.

Шулай итеп, әкиятләр, мәктәпкәчә яшьтәге балаларның этномәдәни компетентлыгын формалаштыру, этнотолерантлык, шәхес тәрбияләү чарасы буларак зур, мөһим роль уйный. Әкиятләр ярдәмендә бала дөньяны акылы белән генә түгел, йөрәге белән дә танып белергә өйрәнә.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Гыйздәтуллина А.М. Биләудәге рәссам.-Яр Чаллы: «Яр Чаллы типографиясе»,2007.- 102бит.
2. Закирова К.В. Ин матур суз: Ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен христоматия.-Казан:Мәгариф,2000.-335 б.
3. Ягъфаров Р. Татар балалар фольклоры. -Казан:«Раннур» нәшрияте,1999-352б.
4. Зарипова Ф.Я. Могҗизалы мәктәп сәхнәсе: Балалар бакчалары тәрбиячеләре .сыйныф җитәкчеләренә ярдәмлек.-Казан:Мәгариф,2003.-255б.
5. Закирова К.В. Әхлак нигезе –матур гадәт(Гаиләдә һәм балалар бакчаларында әдәп- әхлак тәрбияләү):Методик кулланма.-Казан:Мәгариф,2004.-383б.
6. Закирова К.В.Уйный-уйный усәбез. Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма.-Казан:Татар.кит.нәш.,2010.-175б

7. Расскажи мне сказку / Сост. Э.И.Иванова. М.: Изд. «Просвещение», 1993. -464 с.

8. Фесюкова Л.Б. Воспитание сказкой: Для работы с детьми дошкольного возраста. - М.: ООО «Издательство АСТ», 2010. - 464 с.

9. Мультимедийная онлайн-библиотека «Сказки Поволжья».

Р.Р. Габитова, воспитатель
МБДОУ «Детский сад№3 «Кояшкай»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

**Зурлар төркеме өчен шөгыль: «Гөлназның читекләре»**

*Төп сүзләр: милли, татарлар, бизәкләр, асыл, аяк киеме, бөрмәләр, нәфис зәвыгын, мәдәният, орнамент, күз үлчәме, декоратив-гамәли сәнгать.*

Россия үзенең күпмилләтле составы белән уникаль, анда һәр халык үз тарихы, традицияләре, мәдәнияте белән аерылып тора. Буыннан-буынга мәдәни халык кыйммәтләрен саклау һәм тапшыру - бу зур җаваплылык һәм намус вазыйфа.

Идел буенда Россия мөселман мәдәнияте үзәге - бай һәм гүзәл башкаласы булган Татарстан Республикасы урнашкан. Казан - милли татар традицияләренә хәзерге заман тормыш ритмы белән ярашкан шәһәр. Монда буыннан-буынга уникаль һөнәрләр бирелә, аларга бары тик осталардан гына өйрәнергә мөмкин.

Хәзер милли костюм һәм аяк киеме тегү белән махсуслаштырылган җитештерү предприятиеләре шөгыльләнә, анда профессиональ осталар костюм тарихын, аны әзерләү үзенчәлекләрен яхшы белә.

Читекләр - матур, яхшы уйланылган һәм функциональ татар итекләре. Йомшак борын һәм каты арткы ягы читекләрнең үзенчәлекле билгесе булып тора. Бу аяк киеме татарларда киң таралган һәм милли костюмның бер өлеше булып тора. Читекләр шулай ук Себер, Ерак Көнчыгыш, Кавказ халыклары арасында да билгеле. Бу аяк киеме тарихи яктан уңайлы җәяү йөрү өчен билгеләнгән, шул исәптән күчмә халык арасында да. Читекләр аучының аякларын алыштыргысыз, шул ук вакытта аяк табанын һәм балтырларын яхшы саклап, урман буйлап йомшак һәм тавышсыз гына йөрергә булышучы аяк киеме. Бу читекләрне төрле төрдәге табигый күннән тегәләр: бәйрәм була калса - юка һәм эластик сафьяннан, көндәлек вариант сыйфатында хром яки юфть кулланалар.

Хатын-кыз читекләрен төрле төсләргә буялган күн белән бизәү кабул ителгән. Андый читекләр безнең көннәргә кадәр сакланган.

Орнаментны сайлауга килгәндә, ул гадәттә үсемлек мотивлары яки абстракт фигуралар белән тәкъдим ителә, чөнки мөселман дөньясы кагыйдәләре хайваннарны һәм кошларны сурәтләргә мөмкинлек бирми. Канун нигезендә тегелгән аутентик читекләр декоратив-гамәли сәнгать предметы булып тора. Асылда һәр пар үзенчә уникаль.

Мастерлар, авторлар - читек әзерләү традицияләрен саклаучылар, яңа буыннарга әлеге кабатланмас аяк киеме тегү технологиясен бирергә тырышалар.

Балаларны татар милли киеме үзенчәлекләре белән таныштыру һәм читекләргә татар орнаменты элементларыннан бизәкләр төзергә өйрәтү максатыннан мин дә өлкәннәр төркеме балалары өчен «Читеккә бизәк төшерү» исемле мастер-класс конспектын эшләдем.

**Шөгельнең бурычы** булып ир-ат һәм хатын-кыз костюмнарының элементлары һәм үзенчәлекләре турында төшенчә бирү, балаларның иҗади сәләтләрен, күз үлчәмен, хыялын, нәфис зәвыгын үстерү тора. Шулай ук мастер класс сүзлек запасын киңәйтергә (читекләр, калфак, камзул, бөрмәләр, түбәтәй) мөмкинлек бирә. Әйләнә-тирә чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәт тәрбияли. Татар халкының декоратив-гамәли сәнгате белән кызыксыну тәрбияли.

Мастер класс барышында музейга экскурсиягә бардык. Анда татар декоратив-гамәли сәнгате белән таныштык. Татар үсемлек орнаментлары турында әңгәмә уздырдык. Татар милли киемнәре турында илюстрацияләрне, альбомнарны карадык. Трафарет аша милли орнаментлар ясарга өйрәндек. Булачак читекләребезнең фоамиран материалыннан эскизларын кистек.

**Эш барышы:**

Ишеккә шакыган тавыш. (Кулына капчык тоткан курчак керә)

Тәрбияче: Балалар, безгә бүген Гөлназ исемле курчак кунакка килде. Әйдәгез, исәнләшик аның белән.

Балалар: Исәнме, Гөлназ.

Тәрбияче: Аның күлмәге нинди?

Балалар: Матур, озын җиңле күлмәк, бизәкле жилет. Башында калфак. Аякта күн итекләр.

Тәрбияче: Гөлназның кием-салымы ничек дип атала?

Балалар: Татар милли киеме.

Тәрбияче: Татарлар борынгыдан шундый кием киеп йөриләр. Халык осталары аны үсемлек орнаментыннан төзелгән татар бизәкләре белән бизәгәннәр. Сез татар орнаментының нинди элементларын беләсез?

Балалар: Яфраклар, ләлә чәчәкләре, кыңгыраулар, дугалар, дулкынлы сызыклар.

Тәрбияче: Дөрес. Татар орнаментында нинди төсләр кулланыла?

Балалар: Яшел, сары, зәңгәр, кызыл, коңгырт.

Тәрбияче: Дөрес. Балалар, безнең курчагыбыз буш кул белән килмәде. Аның

хәтта капчыгы да татар бизәге белән бизәлгән. Гөлназның капчыгы эчендә нәрсә ятканын беләсегез киләме? Капчык авызын ачканчы табышмак чишнргә кирәк булачак.

Йомшак итеп тегелгән,
Матур бизәп чигелгән
Бәйрәмнәр җитте исә
Аягына кияләр.(*Читекләр күрсәтәм*)

Балалар: Читек.

Тәрбияче: Читек-татар милли киеменнән итекләр. Читек нәрсә белән бизәлгән?

Балалар: Яфрак һәм чәчәкләр белән.

Тәрбияче: Дөрес. Кешеләр мондый аяк киемен кая кияләр?

Балалар: «Сабантуй» бәйрәменә. Татар халык биюенә.

Тәрбияче: Кем мондый аяк киеме кия?

Балалар: Әниләр, әбиләр, кызлар һәм хәтта әтиләр.

Тәрбияче: Минем дә әбием бар, ул да «Сабантуй» бәйрәменә барганда матур бизәкле читекләрен киеп куя.

Тәрбияче: Балалар, сезнең дә матур бизәкле читекләр ясаучы остазлар буласыгыз киләме?

Балалар: Әйе.

Тәрбияче: Барлык остазлар да остаханәдә эшлиләр. Без дә сезнең белән остаханәгә барабыз һәм эскизларыбызны бизәрбез. Гөлназ да остаханәдә булачак. Дөрес утырыгыз һәм эшебезне башлыйбыз.*(Фоамиран материалыннан эзерләнгән читек эскизлары, тюбиктагы буяулар, милли бизәк төшерелгән үрнәкләр куелган өстәл янына киләбез. Балалар эскизларны алалар.)*

Тәрбияче: Балалар, ничек уйлыйсыз, минем кулымда нәрсә?

Балалар: Читек.

Тәрбияче: Әйе, дөрес. Без әлеге читекләребезне гади булмаган ысул белән бизәрбез. Сезнең алдыгызда тылсымлы буяулар. Бу буяулар белән осталар киемнәргә төрле матур рәсемнәр төшерәләр. Иң элек карандашлар белән читек эскизына сезгә ошаган бизәкне ясыйбыз. Шуннан соң төсле тюбикларыбызны алып бизәкләребезне буйыйбыз. Нинди бизәкләр төшерәбез, балалар?

*(Балаларның җаваплары)*

Тәрбияче: Мәликә, син нинди төсләр куланнасың?

Мәликә: кызыл, яшел, сары, ак.

Тәрбияче: Бик яхшы. Балалар, читегебезне бизәгәндә матур, ачык төсләр кулланабыз.

Тәрбияче: Нинди бизәкләр ясыйбыз?

*(Балалар җаваплары)*

Тәрбияче: Эшебезне башлыйбыз!

*(Эш барышында балаларга киңәшләр, күрсәтмәләр, индивидуаль ярдәм итәм,*

*эш тәмамлангач, балаларга күргәзмә оештырырга тәкъдим итәм*).

Тәрбияче: Балалар, карагыз әле, безнең эшләребез белән нинди кызыклы күргәзмә барлыкка килде. Читекләребез кибеп бетсен, ә хәзер мин сезне "Түбәтәй" уенында уйнарга чакырам. Балалар түгәрәк эченә керәбез. Милли музыкага түгәрәк буенча түбәтәй бирәбез. Көй туктала, түбәтәй кемдә кала, шул бала биремне үтәячәк.

**Нәтиҗә:**

Тәрбияче: Балалар, без бүген нәрсә ясадык?

Балалар: читек.

Тәрбияче: Дөрес. Кемнең читеге сезгә күбрәк ошады?

*(Балаларның җаваплары)*

Тәрбияче: Сез читекләрне нинди бизәкләр белән бизәдегез? Сезгә читекләрне бизәргә ошадымы? Ясаган читекләрегезне кемгә бүләк итәр идегез?

*(Балаларның җаваплары)*

Тәрбияче: Барлык эшләр дә бик матур килеп чыкты. Әфәрин, балалар! Курчагыбыз Гөлназ матур читекләргә шатланды, барагызда да рәхмәт әйтте. Сез булдырдыгыз!

**Кулланылган әдәбият:**


1. Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. – Казань, Татарское книжное издательство, 1984.
2. Валеева-Сулейманова, Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана.– Казань, Фэн, 1995.
3. Сатарова, Л. Казанская узорная кожа.– Казань, Магариф, 2004.
4. Этнография татарского народа. – Казань, Магариф, 2004.
5. https://ar.culture.ru/ru/subject/ichigi
6. https://sudaryshka.ru/blog/post24
7. https://nsportal.ru/detskiy-sad/okruzhayushchiy-mir/2019/12/19/masterskaya-po-poshivu-tatarskoy-natsionalnoy-obuvi-ichig
8. https://dzen.ru/media/nashtatarstan/ichigi-kojannaia-tatarskaia-obuv-
9. https://flomaster.club/16066-tatarskie-ornamenty-i-uzory-trafarety.html
10. https://yandex.ru/video/preview/3257233563302791566

Г.Н.Вафина, воспитатель
МБДОУ «Детский сад№3»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

**Этнокультур компетентлыкны балалар бакчасыннан башлап тәрбияләү**

*Төп сүзләр: гореф-гадәтләр, йолалар, милли мирас, чаралар, шөгыльләр, экскурсияләр, кумәклек,дуслык, милли аң.*

Эш тәҗрибәсеннән чыгып «Этнокультур компетентлыкны балалар бакчасыннан башлап тәрбияләү» диеп исемләнгән темага чыгыш ясыячакмын.

Тәрбия, халыкта туган тел белән барлыкка килә. Кешеләрне рухландыручы гореф-гадәтләр, йолалар, буыннан- буынга күчеп, камилләшеп бүгенге көнгә кадәр җиткән.

Бала өлкәннәр белән аралашып кирәкле күнекмәләргә өйрәнә, халыкның гореф-гадәтләрен, йолаларын үзләштерә.

Балалар милли җанлы булып үссеннәр, татар булулары белән горурлансыннар дисәк, һәр гаиләдә балаларга сабый чактан ул халыкның милли мирасын өйрәтү мөһим.

Безнең балалар бакчасында эш барышында мин төрле чаралар, шөгыльләр, экскурсияләр, мини музейлар оештырам.Шулай ук яңарыш методларын кулланам.

Минем эшемнең максаты балаларда этнокультур тәрбия формалаштыру. Бу максатка ирешү өчен төп бурычларны үтәргә кирәк:

1.Балаларны үз халыкларының культурасы белән таныштыру.
2.Балаларда төрле культура халыкларына толерантлык тәрбияләү.
3. Милли байлыкларны белергә теләк уяту.
4. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның иҗади сәләтләрен үстерү.
5. Милли материалны аңлатканда яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу.

Балалар белән эш формаларының берсе һәм иң кирәклесе- уен. Уеннар милләтнең бай рухи хәзинәсе ул.Алар милләт, җәмгыять үсеше процессында яшәү рәвешләрен, социаль, иҗтимагый күренешләрне һәм ерак заманнарда яшәгән бабаларыбызның дөньяга карашын, тормыш-көнкүреш сүрәтмәләрен үзләренә сеңдереп саклап килгәннәр.Шуның өчен уеннар милләтнең этник тарихын өйрәнүдә кыйммәтле чыганак булып хезмәт итәләр.Уен -баланы кызыксындыра һәм җәлеп итә.Милли культураны таныштыруда төрле уеннар кулланыла.

Өстәл уеннары тәрбия чарасы буларак отышлы, алар барышында күмәклек, дуслык, игътибарлылык,ярдәмләшү кебек матур сыйфатлар,шулай ук бала күңелендә туган телне,халкыбызның үткәнен, гореф-гадәтләрен өйрәтә: “Бизәк төзе”, “Парын тап”, “Әкиятне төзе”, “ Кисәкләрне җый”,

“Уйлап тап” шулай ук күгәзмәдә тәгъдим ителгән “Тылсымлы тәрәзчекләр”дигән яңа уенымны күрсәтеп үтәсем килә.

Хәрәкәтле-сүзле уеннар шигырь калыбына салынган булуы балаларда эстетик зәвек тәрбияли,бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен үстерүгә ярдәм итә: “Түбәтәйле”, “Йөзек салыш”, “Урындыклар”, “Юрта”, “Ак калач”, “Чума үрдәк,чума каз” , “Кәрия-Зәкәрия”, “Капкалы”, “Карусель”, җырлы-биюле Идел буе халыклары уеннарын да уйныйбыз.

Төрле шөгыльләр аркылы балаларда милли үз ан тәрбиялибез, бу бәйрәмнәрдә төрле милләт халыкларының эшчән,кунакчыл, ачык йөзле булуларын күрсәтәбез : әкиятләр кую, бәйрәмнәр оештыру.Балалар бәйрәмнәрне аеруча ярата “Сабантуе”, “Сөмбелә”, “Нәүрүз бәйрәме”, “Халыклар дуслыгы бәйрәме”, “Татарстан туган көн” “Каз өмәсе”, квест шөгыльләр.

Экскурсияләр уздыру: Чистаебызның күренекле урыннарына, “Пастернак музеена”, Чистай өязе музеена, Кама яры буенда урнашкан паркка экскурсияләр ясап торабыз.

Мини музейлар: безнең балалар бакчасында “Әбиемнең сандыгы” һәм “Чистай минем туган ягым” дигән мини музейлар бар.Алар группада урнашкан. Мини музейларда татар, рус халкының гореф-гадәтләрен, яшәү рәвешен чагылдырган экспонатлар тупланган. Музейның группада урнаштыруның төп үзенчәлеге: бала экспонатларны күзәтеп кенә калмый, аларны кулына алып тотып карый, уйный ала. Музейдагы экспонатлар балаларны тарихи гасырга алып кайта.

Ата-аналар белән эш: ата-аналар җыелышлары, ата-аналарга консультатцияләр, анкеталар уздыру, эшебездә коар-кодлар куллану, милли темага мастер-класслар үткәрү тора.Минем эшемдә ата-аналар төп булышчылар. Барлык тәрбия гаиләдән башлана.Алар кызыксынып кына калмыйлар, ә төрле экскурсияләр, бәйрәмнәр оештыруда, костюмнар тегүдә, экспонатлар табуда ярдәмчеләрем булып тора. Актив рәвештә “Милли ризыклар” турында оештырылган проектта катнаштылар, “Нәсел шәҗәрәм” дигән проектта буыннар бәйләнешен күрсәтеп эзләнү эшләре алып бардылар, бу эш ата-аналарга да, балалар өчен дә бик кызык булды. “Оста куллар” күргәзмәсендә этиле-уллы гаилә әгъзалары катнашты.

Эшемнең нәтиҗәсе булып шуны әйтәсем килә.Бу эшчәнлек системалы рәвештә алып барыла. Милли компетентлыкны балалар бакчасыннан башлап эшләү билгеле бер нәтиҗәләр бирә.Балаларда милли аң тәрбияләү бары тик бердәм эшчәнлектә генә уңышка ирешелә.

Бала гаилә тәрбияче.Бу өчлек һәрвакыт бердәм булсын.Балаларның киләчәге матур, якты булсын дигән сүзләр белән чыгышымны тәмамлыйсым килә.

**Кулланылган әдәбият:**

1. Ә.Н.Хуҗиәхмәтов. Тәрбия – мәңгелек фәлсәфә. – Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 2001

2. Мусин Ф.М. Татар әдәбияты - Казан: Мәгариф, 2005.

3. Татар халык авыз иҗаты: Хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2004.-

4. Ягъфәров Р. Татар балалар фольклоры. Казан. 2002.

5. Саттаров Г.Ф. Татар исемнәре сүзлеге. Казан, Тат.кит.нәшр., 1981.

6. Саттаров Г.Ф. Исемең матур, кемнәр куйган? Казан, Тат.кит.нәшр., 1989.

8.Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология.- Казан: Хәтер, 1999.

А.Ш. Мингулова, воспитатель
МБДОУ «Детский сад№3»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

## Фольклор - мәктәпкәчә яшьтәге балаларның этномәдәни компетентлыгын үстерү нигезе

*Төп сүзләр: халык авыз иҗаты, гореф-гадәтләр, иҗтимагый тәҗрибә, әхлакый принциплар, халык җырлары, милли уеннар;*

Этнокультура белемен формалаштыру һәм үстерүнең иң нәтиҗәле алымнарының берсе - укыту-тәрбия процессының этнопедагогизациясе. Балаларның этномәдәни компетентлыгын үстерүдә халык авыз иҗаты, яки фольклор аерым урын алып тора. Ул барлык төр һәм жанрларның әсәрләрен үз эченә ала: болар – халык бәйрәмнәре, этнос, әкият, риваять, легенда, мәкаль, әйтем.

Фольклор бик зур тәрбия әһәмиятенә ия. Ул балаларның үткәне һәм бүгенгесе Ватан, башка илләр, халыклар турындагы карашларын баета, халыкларның әхлакый принципларын үзләштерергә ярдәм итә, дөньяның барлык халыкларына карата мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияли, гаделлек тантанасына, киләчәккә ышанычны ныгыта. Халык гореф-гадәтләре балаларны мәдәният дөньясына кертергә ярдәм итә.

Татар халкының фольклоры, мәдәнияте белән, балалар бакчасында танышу, баланың интеллектын формалаштыруның, аның этномәдәни компетентлыгын үстерүнең ышанычлы ысулы, баланың үзе өчен кирәкле иҗтимагый тәҗрибәне үзләштерә торган актив социаль бәйләнеш чарасы.

Татар фольклорын өйрәнү баланы «чит» мәдәниятне якын һәм аңлаешлы итеп кабул итүгә әзерләргә, үз мәдәниятеңне һәм башка мәдәниятне даими идентификацияләү процессын формалаштыруга йогынты ясарга, балада кызыксыну үстерергә мөмкинлек бирә.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны милли мәдәнияткә, фольклорга тартуның беренче адымы - халыкның гореф-гадәтләрен, йолаларын,

ышануларын аңлау, әкиятләр,риваятьләр дөньясына чуму, аларның дәүләт символикасын аңлау.
Эш формалары  төрле булырга мөмкин, мәсәлән:
- халык әкиятләрен тыңлау, аларны сәхнәләштерү;
- балалар әсәрләрен уку;
- табышмакларны чишү һәм искә төшерү;
- мәкальләрне һәм әйтемнәрне искә төшерү һәм аңлау;
- халык җырларын өйрәнү;
- милли уеннарны өйрәнү;
- халык җырчылары  белән танышу, җырлар тыңлау;
- милли мотивлар буенча рәсем ясау;
- халык традицияләре, гореф-гадәтләре, йолалары турында әңгәмәләр;
- музейларга бару;

Эшемдә фольклор әсәрләрдә еш очрый торган геройла рәвешендәге уенчыкларны файдаланам. Өлкән яшьтәге балалар әкиятләр, аларның персонажлары белән таныш инде. Алар үзләре үк әкиятләр сөйләүдә катнашалар. Шул ук вакытта берничә таныш әкият буенча викторина оештырылырга мөмкин.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны башка халык мәдәниятенә китерү, таныштыру югары педагогик осталык таләп итә, чөнки балаларны хәтта кыска фольклор әсәрне дә аңлауга җиткерү кыен, бигрәк тә тәрҗемәдә. Моның өчен махсус күрсәтмә чаралар кирәк. Шуңа күрә мондый мохитне оештыру кирәк, аның ярдәмендә аларны гомумиләштерү һәм танышу тиешле көнкүреш предметларын, иллюстрацияләрне, халык кәсепләре, милли киемнәр үрнәкләрен күрсәтү белән бергә алып барылырга тиеш диеп саныймын.

Балалар, мәсәлән, фольклор әсәрнең танып белү әһәмиятен тавышның эмоциональ сәнгатьле булуы, мимика һәм ишарәләр ярдәмендә аңлауга ирешү җиңелрәк. Өлкәннәрнең һәм балаларның актив иҗат итүчәнлеге, аларның уртак кичерешләре әкият геройларының гамәлләренә, олыларның балалар белән уен бәйләнешенә керә белүенә бәйле.

Халык авыз иҗаты жанрларында эчтәлек һәм форма, максат һәм чаралар бердәмлеге карала: табышмаклар максаты-акыл, зирәклек, мәкальләр максаты- әхлак, җырларда-халыкның тарихы, әкиятләрдә- халыкның хикмәте яшерелгән.

Әкиятләр нәниләрнең рухи үсешендә зур роль уйный. «Әкият аркасында бала дөньяны акылы белән генә түгел, йөрәге белән дә танып белә... Идея тәрбиясенең башлангыч этабы да әкият ярдәмендә була.» Әкиятләрнең борын-борыннан яшь буынны тәрбияләү чарасы буларак яшәп килгәнлеге мәгълүм нәрсә.

Мәкаль ул - үзенең үткенлеге, кыскалыгы көче белән безне шаккатыра торган канатлы сүз. Мәкальләрдә бу халыкның бөтен дөньяга карашы, көнкүреше, характеры, күзәтүчәнлеге һәм хәтта тарихи үткәне чагыла.

Без Идел буенда яшибез. Идел ярларында күп төрле милләт: рус, чуваш, татар, башкорт, мордва, мари, удмурт халыклары гомер кичерә. Аларның һәркайсының гореф-гадәтләре,үзенең фольклоры бар, милли йолалары бар. Шулай ук хәрәкәтле уеннары белән дә аерылып торалар. Халык уеннары балаларга рухи тәрбия бирүдә, гомумкешелек кыйммәтләрен формалаштыруда йогынты ясый.

Шулай итеп, белем бирү процессының этнопедагогизациясе, ягъни фольклорны өйрәнү, балаларның милли һәм дөнья мәдәнияте кыйммәтләрен үзләштерүгә алып бара торган этномәдәни компетентлыкны үстерүнең төп инструментларының берсе буларак карала. Моннан тыш, ул укыту-тәрбия процессында халык педагогикасының чараларын һәм ысулларын куллануны, балаларның милли-психологик үзенчәлекләрен һәм төрле этносларны гаиләдә тәрбияләү үзенчәлекләрен исәпкә алуны күздә тота.

**Кулланылган әдәбият:**


1. “Балалар фольклоры”- Казан Татарстан китап нәшрияты- 1993 г.
2. “Борынгы фольклор”- Казан Татарстан китап нәшрияты- 1994
3. Бакиров М.Х “Татар фольклоры»-Казан «Мәгариф» 2008
4..”Балалар фольклоры”-Казан Хәтер-2009
5.”Татар балалар фольклоры”-Казан “Раннур” нәшрияты,1999
6.“Татар халык иҗаты”- Казан Татарстан китап нәшрияты- 1993 г.
7. “Татар халык уеннары”- Казан Татарстан китап нәшрияты- 1986 г.
8. Р. Ф. Ягъфәров”Энҗе чәчтем-энҗе җыям”-Казан”Мәгариф”2000



Ю.Т.Хаматгалимова, воспитатель
МБДОУ «Детский сад№3»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан


## Мәктәпкә әзерлек төркеме өчен «Иделчеләр-сәяхәтчеләр» шөгыле

*Төп сүзләр:милли кием, калкан, кылыч, таҗ, милли ризык, милли бәйрәм, Идел.*

Тәрбияче балалар белән керә.

-Балалар, карагыз күпме кунаклар җыелган бүген бездә. Исәнләшегез.

- Исәнмесез. Хәерле иртә. Хәлләрегез ничек? (Әйбәт).

-Балалар без сезнең белән нинди Республикада яшибез? (Татарстан)

- Татарстанның башкаласы? (Казан)

- Татарстанның флагында нинди төсләр бар, гербында нәрсә сүрәтләнгән? (Балалар җаваплары)

-Татарстан иң зур Идел буе елгасы янында урнашкан.

Идел ярларына нурлар сибеп

Матур булып ата бездә таң.

Таң шикелле якты Туган илем,

Бәхет биргән җирем — Татарстан

-Идел буенда нинди республикалар тагын уранашкан атагыз? (Чувашия, Мордовия, Республика Марий Эл, Башкирия, Удмуртия)

- Телисезме Идел буенча сәяхәткә китәбез? (Әйе, телибез) Менә каршыбызда «Иделче» турагенствасы. (Өстәл, компьютер, глобус, карта, буклетлар, телефон һәм үзе турагент)

- Исәнмесез!

- Исәнмесез. Без балалар белән Идел буенча сәяхәт итәргә телибез.Безгә нәрсә тәгьдим итә аласыз?

Турагент: Безнең туристик агентлык сезгә Идел буе республикалары буйлап сәяхәт итәргә тәкъдим итә (буклетлар күрсәтә) экскурсоводлар сезгә һәр Республика турында күп кенә кызыклы нәрсәләр сөйләр.

Нәкъ менә бүген, нәкъ менә хәзер, бик зур ташлама белән һәм сезнең өчен генә Идел буеның өч Республикасына-Чуашия Республикасына, Марий Эл Республикасына һәм Башкортостан Республикасына-яна торган тур туры килә!

- Балалар ризамы? Сәяхәткә барабызмы?

Түгәрәккә басыйк, күзләрне йомып үзебезне теплоходта диеп һис итегез.Идел дулкыннарының ничек шаулавын тыңлагыз. Борын белән сулыш алабыз, сулышны авыздан чыгарабыз. (Теплоход сигналы ишетелә, чув.җыры кабына).

Балалар ачыгыз әле күзләрегезне, безнең теплоход тукталды. (Урта Идел картасын алып карый) әйдәгез әле карта буенча карыйк нинди Республикага килеп тукталдык. (Экранда Чебоксар шәхәре. Кунакларны чуваш кызы каршылый, чувашча исәнләшә)

Чуваш кызы: Салам (балалар чуашча исәнләшә)

- Безнең республика башкаласына Чебоксарга рәхим итегез!

Чебоксары - город мой любимый!

Ты красивый, очень молодой.

Возрождаешься и хорошеешь всем на диво.

Чебоксары - город мой родной.

-Тарихы белән бай Чуваш республикасы. Чувашстанның Дәүләт гербы ул калкан, анда «Тормыш агачы» — чуваш халкы үткән озын тарихи юл билгесе ясалган. Ачык сары төсе, кояшны аңлата һәркемгә тормыш бирә. Сигез почмаклы йолдыз

матурлыкны һәм камиллекне белдерә. Флагта без дә «тормыш агачын» күрәбез.

- Чувашларның милли ризыклары: кишер коймаклары, балык белән сөт шорпасы һәм башкалар.

- Чувашларның милли бәйрәмнәре: Сурхури, Калыйм, Ман Тункун, Курак, Акатуй һ. б.

- Милли костюмнарының матурлыгын карагыз.

Ә мин сезгә милли орнамент белән чуваш халкының алъяпкычын бизәргә тәгъдим итәм?(Һәрбер бала, өчен материаллар әзерләнгән, балалар бергә, тылсымлы экранда үрнәк буенча альяпкыч бизиләр).

Чуваш кызы: Бигрәк матур булды ясаган алъяпкычлар.Мин сезгә Республикамның дәүләт символлары сүрәтләнгән магнитлар бирәм.

-Әйдәгез, бергәләп картабызга беркетик.

Бигрәк кызыклы булду бу Чуваш респбуликасына сәяхәтебез. Идел буенчә сәяхәтебезне дәвам итәбез,сине дә чакырабыз.

Хәзер Марий-Эл республикасына барачакбыз. (Экранда Йошкар-Ола шәхәре.Кунакларны марий малае каршылый, исәнләшә (Марий халык көе яңгырый).

Күргәнебезчә, халкыбызның йола, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәрен өйрәнү зур әһәмияткә ия. Дөрестән дә, диннән, телдән башка яши алмаган кебек, халык алардан башка да милләт буларак яшәвеннән туктар иде. Татар халкы һәр

вакыт үзенең йолаларына тугры булды. Чөнки алар безгә бик ерак бабаларыбыздан мирас булып калганнар. Тик онытмаска, сакларга , буыннан-буынга җиткерергә иде аларны. Ул буыннан-буынга күчеп килә торган байлык. Йола, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәребез безнең рихи мирасыбыз, байлыгыбыз.

Матди байлык ул – фани, бетә торган, вакытлы нәрсә, ә рухи байлык, акыл көче белән хасил булган дөньяга караш, кешеләрнең мөгалләмәсе, гореф-гадәте - мәңгелек.

Кыскасы, безнең максатыбыз туган телебезне, тарихыбызны, рухи байлыкларыбызны, гореф-гадәтләребезне өйрәнеп, буыннар арасында ныклы бәйләнеш булдыру, бөек милләт булып яшәвебезне дәвам итү.

Халык бәйрәмнәре һәм йолалары кешене тормыш тәртипләренә һәм таләпләренә күнектерергә ярдәм итә. Бу бәйрәмнәрне халыкның олысы-кечесе бергәләп уздыра. Балалар бәйрәмнәрнең тәртибен, йоласын кечкенәдән үк белеп, күреп, өйрәнеп үсәргә тиеш. Балаларга кече яшьтән үк әдәплелек, инсафлык, мәрхәмәтлелек тәрбияләүдә әти-әниләр, тәрбиячеләр зур эш алып баралар. Балаларга үз-үзен тота белү, аралаша белү күнекмәләрен балалар бакчасында һәм гаиләдә өйрәтергә кирәк. Әгәр дә без балаларны шушы тәртиптә тәрбияләсәк, шул чагында гына милләт, халык өчен тәрбияле балалар үстерербез .

Әйтеп үткәнебезчә, милли тәрбия балалар бакчасында ук башланырга тиеш, алай гына да түгел, бала дөньяга килгәч тә, гаиләдә милли тәрбия формалаштыруга юнәлгән эш- гамәлләр башкарыла. Без дә балаларыбызга үз чиратыбызда милли тәрбия бирү максатыннан күп эшләр башкарабыз. Балалар бакчасында ”Әби- бабай истәлеге” дигән музей оештырдык. Туган якны өйрәнү, туган якның мәдәнияте, истәлекле урыннары белән таныштыруны музейлардан башка күз алдына да китереп булмый. Әлеге музейны оештыруның максаты балаларга кече яшьтән үк үзләренең туган төбәкләренә, туган шәһәрләренә мәхәббәт хисләре тәрбияләү.Туган яктагы халыкларның тарихын, туган якка хас милли гореф- гадәтләрен, йолаларын белеп, аңлатып үстерү.

Музейда балалар белән төрле шөгыльләр, тәрбия чаралары үткәрәбез, музейдагы җиһазлар, аларның исеме белән таныштырабыз, аларның тарихи эзлеклелеге, әйберләрнең тормыш шартларына бәйле рәвештә кулланылуларын күрсәтәбез. Тәрбия чараларында балаларны музей экспонатлары белән таныштырып кына калмыйбыз, аларның тарихын, көнкүрештә ни өчен кирәклеген дә аңлатабыз. Бу эшебез сөйләүгә генә кайтып калмый, төрле уен формаларда тормышка ашырыла.

Кыскасы, безнең максатыбыз туган телебезне, тарихыбызны, рухи байлыкларыбызны, гореф - гадәтләребезне өйрәнеп, буыннар арасында ныклы бәйләнеш булдыру, бөек милләт булып яшәвебезне дәвам итү.

Татарстан халыкларының үзара дус, тату яшәве – бөтендөнья өчен толерантлык үрнәге булып торуын да күрсәтә. Халыклар арасында дуслык

бәйләнешләрен ныгытуда бәйрәмнәрнең роле зур, чөнки алар аша халыклар бер - берсенең мәдәниятен, яшәү рәвешен, гореф-гадәте, йолаларын өйрәнә һәм шулар аша бер - берсенә хөрмәт тәрбияли, үз итә, дуслыгын ныгыта.

Бу зур җиңүебездә эти - әниләрнең дә өлеше бик зур. Гаилә белән бакча бердәмлеге булган очракта гына зур уңышларга ирешеп була.

Яшь буынны халкыбызның рухи һәм мәдәни хәзинәләре нигезендә тәрбияләү, балаларда милли үзаң формалаштыру һәм шуның аша туган телен, халкын ихтирам итүче, аның тарихын өйрәнүгә, үстерүгә сәләтле, рухи - әхлакый һәм белем дәрәҗәсе ягыннан камил, киң карашлы шәхес тәрбияләү – безнең төп бурычыбыз.

Гореф - гадәтләр, йола - бәйрәмнәр - безнең бабаларыбыздан калган иң кыйммәтле мирас икәнен онытмасак, милләтебез яшәр, телебез сакланыр.

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**

1. Зиннурова Ф. М. “Үз илемдә, үз телемдә”. Тәрбиячеләр өчен методик кулланма. - Казан:Мәгариф, 2009.
2. Закирова. К. В. “Балалар бакчасында әдәп- әхлак тәрбиясе: методик кулланма. -Казан: Беренче полиграфия компаниясе,2013.
3. Балачак аланы: Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия. - Казан: РИЦ, 2011.
4. Күңел ачыйк бергәләп: Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм музыка җитәкчеләре өчен ярдәмлек.- Казан: Мәгариф, 2003.

Л.А. Юнусова, А.Ф.Шайдуллина, воспитатель по обучению
татарскому языку, старший воспитатель
МБДОУ «Детский сад №7»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

## Презентация пособия - лэпбука по этнокультурному компоненту «Народы Татарстана – башкиры, марийцы, мордва, удмурты, чуваши»

*Ключевые слова: этнокультурный компонент, знания, культура, традиции, этнокультурная среда.*

В связи с введением федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования роль этнокультурного компонента образования сегодня особенно актуальна. Под этнокультурным компонентом подразумевается всё то, что способствует развитию творческих возможностей ребёнка, даёт полное представление о богатстве национальной культуры,

укладе жизни народа, его истории, языке, духовных целях и ценностях, что способствует развитию всесторонне развитой, гармоничной личности, патриота своей Родины, толерантного к разным народам.

Этнокультурный компонент пронизан жизнью в детском саду. Сопровождает детей с ясельной группы до подготовительной. В виде сказок, пословиц, небылиц, народных и дидактических игр. Кругозор детей расширяется в обрядах, праздниках и обычаях.

Для успешной работы воспитателя в условиях этнокультурного компонента необходимо создание системы работы по приобщению детей к истокам народной культуры. Чтобы ребенок почувствовал уникальность своего народа, знал историю своей семьи, страны, мира, возлюбил свою родину, пришел к пониманию и осознанию собственной неповторимости и значимости каждого человека, живущего на земле. Работая по данному направлению, мы рассмотрели несколько путей введения этнокультурного компонента в воспитательно-образовательный процесс дошкольного учреждения.

Основным видом деятельности дошкольника является игра. Мы считаем, что в игровой форме детям легче знакомиться с народной культурой, с культурными достижениями других народов, воспитывать дружеские отношения к людям разных национальностей.

Работая с детьми, мы пришли к такому выводу, что у детей сложились представления о русской и татарской культуре, а вот о культуре, быте, жизни других народов, населяющих республику Татарстан у них недостаточные знания. Требуется пополнить знания о различных компонентах национальных культур народов Татарстана. Это подвело нас к созданию авторского пособия – лэпбука «Народы Татарстана – башкиры, марийцы, мордва, удмурты, чуваши».

**Паспорт лэпбука «Народы Татарстана – башкиры, марийцы, мордва, удмурты, чуваши»**



| | |
|---|---|
| **Возрастная группа** | Старшая, подготовительная группы |
| **Образовательная область** | Познавательное, речевое, социально-коммуникативное, художественно-эстетическое развитие |
| **Формат разработки** | Авторское дидактическое пособие - лэпбук |
| **Цель создания пособия** | Формирование познавательного интереса к этнокультурным ценностям, чувства принадлежности к своей стране. |
| **Задачи** | Познакомить с культурой и традициями народов Татарстана: башкир, марийцев, мордвы, удмуртов, чуваш.<br>Стимулировать попытки самостоятельного познания детьми окружающего мира.<br>Воспитывать любознательность и толерантность. |
| **Составляющие пособия** | **1. Игра: «Символика народов»**<br>**Задачи:** познакомить с символикой народов Татарстана, формировать уважительное отношение к символам, воспитывать любовь к Родине, гражданско-патриотические чувства.<br>**2. Игра: «Народы Татарстана»**<br>**Задачи:** познакомить с народами, населяющими республику Татарстан, с национальными костюмами, учить узнавать по внешним признакам, воспитывать любовь к малой Родине<br>**3. Игра:** «Достопримечательности».<br>**Задачи:** познакомить с достопримечательностями народов Татарстана, развивать любознательность, расширять кругозор.<br>**4. Игра: «Собери орнаменты»**<br>**Задачи:** познакомить с национальными костюмами народов Татарстана, закрепить знания об орнаментах, воспитывать уважение к культуре и традициям разных народов.<br>**5. Игра: «Накрой на стол»**<br>**Задачи:** познакомить с традиционными национальными блюдами народов Татарстана, закрепить названия блюд, учить узнавать по внешним признакам, развивать память, речь.<br>**6. Игра: «Музыкальные инструменты»**<br>**Задачи:** познакомить с национальными музыкальными инструментами, закрепить |

| | |
|---|---|
| | названия.<br>**7. Игра**: **«Подбери национальный костюм».**<br>**Задачи:** познакомить с народами, населяющими республику Татарстан, с национальными костюмами, учить узнавать по внешним признакам, воспитывать любовь к малой Родине.<br>**8. Игра: «Укрась рубашку».**<br>**Задачи:** познакомить с народами, населяющими республику Татарстан, с национальными костюмами, учить узнавать по внешним признакам, воспитывать любовь к малой Родине.<br>**9. Игра:** «Сказки народов Поволжья»<br>**Задачи:** закрепить знания детей о народных сказках Поволжья, умение узнавать и называть сказки по иллюстрациям, по эпизодическим сценкам, развивать интерес, воображение, речь. Воспитать положительные эмоции, дружески взаимоотношения. |
| **Возможности использования пособия** | Используется в игровой деятельности, режимных моментах, индивидуальной работе с детьми, организованной образовательной деятельности. |

**Вывод:** Этнокультурный компонент повышает эффективность в воспитании образовательного процесса дошкольного учреждения. К моменту выпуска из детского сада, дети имеют устойчивое, сформированное представление о культуре своего народа, имеют некоторые представления о культурно-исторических событиях, культурных ценностях. Довольно высокие показатели по развитию речи и игре. Также дети имеют более высокий уровень познавательного развития, обучаемости.

**Список использованной литературы:**

1. Ганиева М.А. Этнокультурный компонент в образовательном процессе дошкольного образовательного учреждения / М.А. Ганиева. — Текст: электронный // NovaInfo, 2017. — № 62. — С. 327-331. — URL: https://novainfo.ru/article/11908
2. Шаехова Р.К. «Сөенеч. – Радость познания: региональная образовательная программа дошкольного образования» / Р.К.Шаехова.- Казань: Магариф-Вакыт, 2016.- С.6 -26.

А. Р. Булатова, Г.И. Закирова,
музыкальный руководитель,
воспитательпо обучению детей татарскому языку
МБДОУ «Детский сад № 6 »
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

## *Квест-игра «Тайны народов Поволжья»*

*Ключевые слова:Родина, игры народов Поволжья, домовой, Сөмбелә, шамаиль, оберег.*

**Цель квест игры**: Формирование у детей устойчивого интереса к народному творчеству.

**Задачи квест игры:**

1. Продолжать знакомить детей с разными народами, населяющими Россию. Побуждать детей уважительно относиться к культуре разных народов.
2. Формировать чувство гордости за Родину, поддерживать интерес к истории и культуре Поволжья и народов, её населяющих.
3. Способствовать позитивному эмоциональному развитию, формировать навыки взаимодействия со сверстниками; воспитывать доброжелательное отношение к сверстникам, закреплять умение работать в команде.

**Участники**: дети старшего дошкольного возраста 5-7 лет

**Станции**: Мастерская, Загадки старины, Познавательная, Игры народов Поволжья.

**Необходимые ресурсы**: предметы народно-прикладного творчества, проектор; магнитофон, маршрутные листы, чугунок, ухват, лапти, скатерть, ложка, полотенце, веник, матрешка, дымковская игрушка, платок.

**Предварительная работа**: знакомство с разными видами росписей, с костюмами народов Поволжья; рассматривание картины, чтение потешек, поговорок, сказок, рассказов про народное творчество; знакомство с народной музыкой и играми разных народов Поволжья; знакомство с предметами быта народов Поволжья.

### Ход квеста:

**Организационная часть**

**Домовенок Кузьма**: Здравствуйте, ребята! Я – Домовой Кузьма! А вы знаете, что домовые есть в каждом доме. Русские люди верили в то, что, если с домовым поддерживать хорошие отношения (обращаться к нему с ласковым словом, оставлять немного вкусной еды), он будет платить добром за добро (ухаживать за скотиной, помогать содержать дом в порядке, предупреждать о грозящем несчастье). Верили, что он бережет детей, любит с ними играть и шалить. Люди всегда с уважением относились к домовому.

**Мотивационная часть**

**Домовенок Кузьма**: Ребята! Я пришел к вам за помощью, у меня задание от своей бабушки. Бабушка мне предложила узнать тайны народов Поволжья и найти обереги, которые помогают защитить дом от бед, ненастья. Но я не знаю, какие

традиции и обычаи существуют у других народов Поволжья. Для путешествия по нашей Республике, нам поможет карта. Ребята, поможете мне узнать тайны народов Поволжья и найти обереги?(Да.). Давайте вспомним, какие народы живут в РТ. Посмотрите на экран! И вы увидите к каким народам мы отправимся в гости. *(Дети вместе с Кузьмой рассматривают карту).*С традициями какого народа мы познакомимся?/с традициями татарского, русского, чувашского и башкирского народа/*(Домовенок Кузьма вместе с детьми отправляются в путешествие).*

**Практическая часть**

**Станции:**

**1. Мастерская (*Татарская*) (Детей встречает Татарка)**

-Исәнмесез.Здравствуйте ребята. Я – татарочка!Меня зовут Алсу. Сегодня хочу вас познакомить с праздником Сөмбелэ. Это татарский национальный праздник- праздник урожая. Его отмечают в день осеннего равноденствия, когда день и ночь – уравниваются. В это время уже урожай убран, осенняя посевная закончена и люди устраивали этот праздник./*показывает хлеб/*Балалар, бу нәрсә?\/ипи/ Әйе.Ипи тәмлеме?/Әйе/Самый дорогой подарок осени – это хлеб. Не зря в народе говорят "Ипи,тоз – якты йөз"/Хлеб всему голова/

На этот праздник готовили очень много угощений. И конечно же пекли вкусный хлеб, пироги и булочки.Сегодня мы приготовим с вами хлебобулочные изделия под названием «Колоски»./*татарочка вместе с детьми изготавливают "колоски"*/

Молодцы ребята, вы справились с заданием! На прощание я хочу вам подарить оберег под названием «Шамаиль». Шамаиль – это изречение из Корана, которое вешали на стены, крепили на почетном месте или над входом в дом.

**Домовенок Кузьма**.Спасибо большое.И мы отправляемся дальше./*смотрят карту./*

**2. Загадки старины (*Русская*) ( Детей встречает русская девушка)**

- Заходите гости дорогие. Я –русская девушка! Меня зовут Маруся. Перед вами на столе лежат старинные вещи, предметы быта, которыми пользовались наши предки. Ваша задача отгадать мою загадку и назвать предмет, который соответствует загадке.

Загадки:

1.Не бык, а бодает,
Не ест, а еду хватает,
Что схватит, отдает,
А сам в угол идет.
Мочили, колотили(ухват)

2. В руку мы её берём,
С супом в рот себе несём.
Только ешьте осторожно,
Суп горячий невозможно,
Ешьте, дети,понемножку,
Помогает есть нам… (Ложка)

3. Из горячего колодца через нос водица льётся. (самовар)

4. Не ботинки, не сапожки,
Но их тоже носят ножки.
В них ходили раньше люди,
И плели из лыка,

А чтоб с ножки не спадали,
Их верёвкой привязали. (Лапти)
5. Стригли, щипали, а после чесали,
Чисто, пушисто – к доске привязали!(Прялка)
6. Рядом разные подружки,
Но похожи друг на дружку.
Все они сидят друг в дружке,
А всего одна игрушка. (Матрешка)
7. Веселая белая глина,
Кружочки, полоски на ней.
Козлы и барашки смешные,
Табун разноцветных коней.
Кормилицы и водоноски,
И всадники, и ребятня,
Собачки, гусары и рыбки.
А-ну, отгадайте, кто я? (Дымковская игрушка)

**Русская**: Молодцы! Справились с заданием.Я хочу подарить вам оберег подкову. Подкову вещают над дверью, чтобы защитить от злых сил, дурного глаза людей, которые настроены к семье отрицательно

**Домовой Кузьма**. Спасибо. Давайте посмотрим на нашу карту куда же мы отправимся дальше.

**3. Познавательная (*Чувашская*) (Детей встречает Чувашка)**

-Сывлах сунатап! Добрый день, дорогие гости. Я – чувашка! Зовут меня Илемпи. Наша республика Чувашия щедра и богата.У нас очень необычные национальные костюмы.

1 слайд – национальный костюм. Наш костюм очень яркий. Основными элементам чувашского национального костюма были: платье-рубаха, фартук, головной убор и нагрудные украшения и поясные подвески. Зеленый цвет- цвет растительности. Желтый – цвет солнца , источник жизни. Красный – цвет счастья, жизни и земли. Давайте рассмотрим вышитые узоры внимательнее. Костюмы украшены необычной вышивкой, вышивали разные красивые орнаменты своими руками, Это не просто набор каких-либо узоров, в старину они многое обозначали: круг- солнышко, квадрат или ромб- земля, крест- оберег от злых сил, извилистая линия- вода. Умелицы украшая этими знаками свою одежду верили в то, что это принесет им счастье, здоровье, хороший урожай, спасет и убережет от злых сил.которые являются оберегами для чувашского народа. А оберег – это защита от злых сил.

2 слайд – Собери в дорогу (пояс, головной убор и т.д.).Предлагаю поиграть в игру «Модельеры ».(*Игра на интерактивной доске*).

- Молодцы! Справились с заданием. Я хочу подарить вам наш оберег под названием «семья»,которая означает верность, единство семьи.

**4. Игры народов Поволжья(*Башкирская*) (Детей встречает башкирка)**

**Башкирка**: Здравствуйте ребята! Я приехала к вам из далека, с республики Башкирия, я-Башкирка! Меня зовут Зухра. Посмотрите, это наш национальный костюм. Нравится вам мой наряд? (Да).Мы любим петь ,танцевать и конечно же играть разнообразные игры. А вы любите играть? (Да) Сегодня я вас познакомлю с башкирской игрой «Голуби»!/*объясняет правило игры/Игра проводится 2 раза.*
Голуби.

На площадке чертятся две параллельные линии на расстоянии 5-8 метров, вдоль этих линий чертятся круги («гнезда»). Дети стоят в кругах («гнездах») напротив друг друга. Водящий - «пастух», с закрытыми глазами ходит между шеренг и произносит три раза текст:
«Гур – гур, голуби
Для всех нас одно гнездо»
С окончанием слов дети меняются местами («гнездами») – бегут в противоположные «гнезда». Пастух открывает глаза и старается занять пустое «гнездо». Оставшийся без «гнезда» ребенок «голубь» становится «пастухом».
Правила: меняться местами можно только тогда, когда пастух произнесет текст три раза.
- Молодцы! Хорошо мы с вами поиграли! Я хочу вам подарить наш оберег «мешочек счастья». Оберег от «злых сил», негатива и приносит удачу.

**Заключительная часть**

Пройдя все станции, дети и взрослые (герои квеста) собираются в музыкальном зале. Домовенок Кузьма благодарит детей за интересное путешествие.

**Домовенок Кузьма**:Вот мы с вами и побывали в гостях у разных народов. И узнали с какими традициями ,обычаями и оберегами живут народы Поволжья./*Татарочка угощает детей испеченными “колосками”.*

## Список литературы


1. Аникин В. П. Русские народные пословицы, поговорки, загадки и детский фольклор. М.: Государственное учебное педагогическое издательство, 1957. 240с.
2. Гарәфиева Г.З.Сөмбеләне кем белә?/Балалар бакчалары тәрбиячеләре һәм музыка җитәкчеләре өчен методик ярдәмлек.-Казан:Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ),2003.-191 б.
3. Культура, искусство татарского народа: истоки, традиции, взаимосвязи: - Казань: - ИЯГИ им. Г. Ибрагимова, 1993 - 138 с.
4. Народы Поволжья:культура,обычаи,праздники,символика.(Интернет ресурс).Национальная библиотека Республики Татарстан https://kitaphane.tatarstan.ru/peoples.htm
5. Обереги у башкир.(Интернет ресурс).Библиотека нематериального культурного наследия Республики Башкортостан https://kitaplong.ru/obereg_rus
6. Подкова в русской культуре.(Интернет ресурс).Славянская лавка https://www.slavyarmarka.ru/podkova-kak-universalij-obereg/
7. Толкование основных символов чувашских узоров.(Интернет ресурс).Чувашский народный сайт.- https://ru.chuvash.org/wiki/
8. Шамаиль в Исламе.(Интернет ресурс).Татарская культура,искусство,традиции. https://tatobzor.ru/tatarskij-shamail

Э.А. Закирова, воспитатель,
МБДОУ «Детский сад
комбинированного вида№ 2»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

# Татар халык сәнгать культурасын өстәмә белем аша киңәйтү

*Төп сүзләр: Ватан, хәзинә, мәдәният, шарты, хис, иҗади, сәнгать, шәхес, сәләт.*

2022 елның сентябрь аеннан безнең зурлар төркемендә «Теремкәйдә», «Хәзинә» дип аталган түгәрәк үткәрелә башлады. Хәзерге вакытта балалар иҗатын үстерү проблемасы теоретик һәм практик мөнәсәбәтләрдә иң актуаль булып тора: сүз шәхеснең индивидуаль үзенчәлеген формалаштыруның мөһим шарты турында бара. Балалар тәрбияләүдә халык декоратив сәнгатенең роле һәм әһәмияте турында күпләр язган. Алар билгеләп үткәнчә, сәнгать Ватан, аның мәдәнияте турында беренче якты, образлы күзаллауларны уята, матурлык хисе тәрбияли, балаларның иҗади сәләтләрен үстерә.

Безнең вакыт катлаулы-социаль үзгәрешләр чоры. Сәяси бураннар һәм тәртипсезлек. Алар безнең һәрберебезнең тормышына туры мәгънәдә кереп киткән. Халык уеннары, уеннар һәм уенчыклар компьютер уеннарына алыштырыла. Асылда, бу кешенең табигатенә ят. Ватанын белүче һәм яратучы гражданин һәм патриотны тәрбияләү-аеруча актуаль бурыч бүгенге көндә үз халкының рухи байлыгын тирәнтен белмичә, халык мәдәниятен үзләштермичә уңышлы хәл ителә алмый.

Халык декаротив-гамәли сәнгате матурлыкка сизгер мөнәсәбәт тәрбияли, гармонияле үсеш алган шәхес формалашуга ярдәм итә. Тирән сәнгать традицияләренә нигезләнеп, халык сәнгате юкка чыга, киләчәк кешесенең формалашуына файдалы йогынты ясый. Декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре кешеләрнең тормышына ешрак үтеп керә. Декоратив сәнгать әйберләренең матурлыгын күрү, аларны ясарга тырышу, бу балалар өчен бик кызык.

Балаларга өстәмә белем бирү программасы актуаль, чөнки ул сәнгать образын, сүзләрне, сәнгать образының нигезләрен, халык сәнгать культурасының гомумкешелек кыйммәтләре белән бәйләнешен киң һәм күпьяклы ачып бирә. Шул ук вакытта балаларның үзләренең сәнгать-иҗади активлыгы процессында иҗади тәҗрибәсен үстерү гамәлгә ашырыла.

Программа баланы иҗат дөньясына кертә, үз-үзенә, үз сәләтләренә ышанырга мөмкинлек бирә, укучыларда сынлы, сәнгать - конструкторлык сәләтләрен, стандарт булмаган фикерләүне, иҗади шәхесне үстерүне күздә тота.

**Максат:** балаларда сәнгать мәдәниятен, матди һәм рухи мәдәниятнең состав өлеше буларак формалаштыру, сәнгать-иҗади активлыкны үстерү, татар халкының декоратив-гамәли сәнгатен үзләштерү.

**Бурычлар:**

• татар халык иҗатының килеп чыгышын ачу;

• татар халык декоратив-гамәли сәнгате өлкәсендә кызыксынучанлык уяту;

• балаларда үз Ватанына, татар халкының традицион халык сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү.

**Балалар белән эшләүне оештыру**

Программа атнага, көннең икенче яртысында 2 дәрес үткәрелә. Елына гомуми дәресләр саны-64, дәресләр вакыты - 25 Мин.

Программа 5-6 яшьлек балалар белән эшләүгә юнәлтелгән һәм бер ел уку өчен исәпләнгән.

**Түгәрәк дәресләрендә куллана торган ысуллар:**

- сөйләшү, хикәя, әкият;
- иллюстрацияләр, көнкүреш әйберләре,
- Сәнгать, үрнәкләр турында уйлау;
- эш эзлеклелеген башкару техникасын күрсәтү;
- Ата-аналар белән эш.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

Укыту нәтиҗәсендә, әлеге программа буенча балалар:

• татар халык декоратив-гамәли сәнгате тарихы белән танышачаклар;

• игътибар, хәтер, уйлау, кулларның Яхшы моторикасын һәм күзне үстерәчәкләр;

• сәнгать, иҗат һәм фантазия үстерәчәкләр;

• хезмәт культурасы күнекмәләрен үзләштерәләр;

- аралашу сәләтләрен яхшырталар һәм коллективта эшләү күнекмәләрен үзләштерәчәкләр

Һәрбер бала дөньяга рәссам булырга килми, ләкин сәнгать үсешенең билгеле бер потенциалы бар, һәм бу потенциалны ачарга кирәк.

Педагогның төп бурычы-балаларны кызыксындыру, йөрәктән кабызу, аларда үз фикерләрен һәм зәвыкларын мәҗбүр итмичә иҗади активлык үстерү. Педагог балада аның иҗади сәләтенә, индивидуальлегенә, кабатланмаслыгына, яхшылык һәм матурлык эшләүгә ышаныч уятырга, кешеләргә шатлык китерә.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Татар халкының йолалары һ҈ем б҈ейр҈емн҈ере /Татарстан Милли к-хан҈есе; Т҈ҫз.З.҈Ѳ.Җамалиева. Казан:милли китап, 2000.
2. Р.Ягъф҈еров. Уен –күңел б҈ейр҈еме.- Казан:М҈егариф,2009.
3. Ш҈ейм҈ерданов, Р.Сибгатуллин. татар милли педагогикасы. Казан: Матбугат.,2004.
4. Баязитова Ф. Татар халкының б҈ейр҈ем һ҈ем к҈ҫнкүреш йолалары. – Казан:Татар кит.н҈ешр., 1995.
5. Ягъф҈еров Р. Халык уеннары//М҈егариф. – 2002. - №1.

А.И. Аминова, Д.Ф.Сафина;
воспитатели
МБДОУ «Детский сад №25»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

## Балалар бакчасында театр эшчәнлеге аша балаларга милли тәрбия бирү

*Төп сүзләр:Заман,чор,әдәбият, әдәпсезлек, әхлак, кагыйдә, нигез, битараф.*

Без яшәгән заман- тирән үзгәрешләр һәм үзгәртеп корулар чорына туры килә. Бүгенге көндә балаларда туган телебезгә, милләткә һәм аның гореф-гадәтләренә, йолаларына мәхәббәт тәрбияләү- иң мөһим бурычларның берсе. Бала үзен чын кеше итеп тойсын өчен, аңарда туган телгә мәхәббәт, татар халкының тарихы һәм сәнгатенә кызыксынучанлык, милли горурлык хисе тәрбияләргә, халкыбызның борынгы гореф-гадәтләрен, экиятләрен, йолаларын өйрәтергә кирәк. Хәзерге заман чорында балаларның күбесе экияттә тәрбияләнми, ә күберәк заманча мультфильмнар карый. Күп әти-әниләрнең бала белән китап укырга вакытлары җитми. Әлеге күрсәткечләрдән чыгып балалар һәм ата-аналар тарафыннан өйдә балаларга матур әдәбият уку әз бирелә. Шул уңайдан без бала тәрбияләү үсешендә экиятләргә, сәхнәләштерүгә күберәк басым ясарга тырышабыз.

Хәзерге чорда радио һәм телевидение, урам йогынтысы балаларның аңына, рухына әдәпсезлек үрнәкләрен сеңдергән заманда, милләтнең гасырлар буе формалашкан тәҗрибәсе, әхлак кагыйдәләре югала бара. Менә шуның өчен дә мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә нәниләргә халкыбыз хәзинәләре нигезендә милли үзаң тәрбияләүгә аеруча зур игътибар бирү безнең максат булып тора. Булдыра алганча, төрле юнәлештә, төрле чаралар белән укыту-белдерү, күрсәтү, төшендерү, үрнәк бирү, ышандыру балалар тәрбиясенең үсешенә ирешү, әхлаклы, зыялы, сәләтле буын тәрбияләү безнең бурычыбыз дип саныйбыз.

Татар халкын милләт буларак саклап калу, үстерү, үткәннәр турында түкми-чәчми балаларыбызга тапшыру — хәзерге буынның төп вазифасы. Күңелендә аз гына милли хисе булган кеше дә моңа битараф кала алмый торгандыр. Халкыбыз хәзинәләре - сабыйларга аң-белем һәм милли тәрбия бирү өчен иң шифалы чишмә.

Сабый чактан ук бала ана телен ишетә, экиятләр аңа дөнья тәрәзәсен ачалар, балачакны эмоциональ яктан бизиләр, ягымлылык, өмет, ышаныч уяталар. Әкиятләрне сәхнәләштерү балаларны дулкынландыра, мавыктыра, көлдерә, елата. Һәр халыкның үз экиятләре бар, алар барысы да буыннан буынга әхлакый кыйммәтләрне тапшыралар. Балаларны туган халкыбызның үткәне, әби-бабаларыбызның гореф-гадәтләре, гаилә шәҗәрәсе, йолалары һәм

бүгенге тормыш белән таныштыру зарур. Халык җәүһәрләрен балалар җиңел, табигый кабул итәләр. Аларда юмор да бар, ямансулык та, бер-береңә, иптәшләреңә, үз туганнарыңа һәм иң мөһиме төрле милләт халкына тирән мәхәббәт ята.

Сәхнәләштерү эшчәнлеген алып барганда, һәр бала үзенең кичерешләрен, тойгыларын. теләкләрен, карашларын гадәти сөйләшкәндә генә түгел, ә чит тыңлаучылар алдында күрсәтә алырлык шартлар тудырырга һәм яшьтән үк өйрәтергә кирәк. Еш кына без кин белемле, сәнгатьле сөйләшә белүчеләрне оялчан икәнен, чит кешеләр алдында югалып калуларын күзәтәбез. Әлеге проблемалар булмасын өчен, балалар бакчасында әкиятләр сәхнәләштерү бик зур булышлык күрсәтә. Сәхнәләштерелгән әкиятләр балаларны шатландыралар. Театрда катнашып, балалар тирә-юнь белән, төсләр, авазлар белән танышалар, ә уйланылып куелган сораулар балаларны анализларга, уйланырга, нәтиҗәләр ясарга ойрәтә. Сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү барышында, сизелмичә баланың сүз байлыгы арта, бала чиста, дөрес, аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәнә. Сүзлек формалаша- яңа сүзләр белән баетыла. Әкиятне укып бетергәч, балаларга нинди дә булса җөмләне тәмамларга, кабатларга, эчтәлеген сөйләргә тәкъдим ителә. Аннан кечкенә хикәяләр алына. Әкренләп монологик сойләм генә түгел, ә диалогик сөйләм дә үсә. Аваз культурасы өстендә эшләнелә. Бала күп нәрсәне исендә калдыра. Аның хәтере үсә. Рольне уйный- уйный, бала әкият дөньясына кереп китә, куелган максатлар аша милли тәрбия бирә. Сәхнәләштерү эшчәнлеге күрсәтүенчә, бала ялгышырга мөмкин, ә менә әкият герое ялгышырга тиеш түгел. Шуңа күрә балалар әкият уйнаганда, сүзләрен 2-3 мәртәбә тырышыбрак өйрәнәләр. Аларнын бу шөгыльләрдән сон хәтерләре яхшыра. Яраткан геройлар балаларга үрнәк булалар.

Сәхнәләштерү эшчәнлеге балаларга проблемалы ситуацияләрне чишәргә булыша;-персонаж аркылы оялчанлыкны. кыюсызлыкны бетерергә, сәнгатьле игеп сөйләргә булыша. Рольне уйнау, баланы башка персонаж алдында чиста, аңлашылырлык итеп аңлатуны таләп итә. Театр бала өчен яп-якты истәлек булып кала.

Милли тәрбия эшен оештырганда, тәрбиячедән осталык, иҗат фантазиясе таләп ителә. Шуңа күрә дә балалар белән эшне оештыруга җитди әзерләнәбез. Эшчәнлекне барлык заман таләпләрен исәпкә алып планлаштырабыз. Татар халкы- әкиятләргә бай халык. Ул иҗат иткән әкиятләр эчтәлек һәм формалары ягыннан төп өч төргә буленәләр: хайваннар турындагы әкиятләр, тылсымлы әкиятләр, тормыш-көнкуреш әкиятләре.

Әкиятләр –әхлакый тәрбия чыганагы, хис тәрбияләү чыганагы. Балалар әкиятләрне тыңлап, театральләштереп уңай һәм тискәре сыйфатларны аера белергә өйрәнәләр. Күңелләре белән гаделлекнең, дөреслекнең җиңүен телиләр. Әкиятләрне театральләштергәндә балаларда милли тәрбия ныгытыла: балалар өлкәннәр белән исәнләшергә, саубуллашырга өйрәнәләр, ягымлы сүзләр белән бер-берсенә эндәшәләр. Иң якын кешене-әнине

борчымаска өйрәнәләр. Һәр әйбернең үз урыны барлыгын һәм аны һәрвакыт урынына куярга өйрәнәләр. Өлкәннәр хезмәтен хөрмәтләргә, хезмәт эшчәнлегендә катнашырга омтылу һәм өлкәннәргә ярдәм итү теләге тәрбияләнә.

Нәтиҗә итеп шуны әйтергә була: балалар тәрбияләгәндә халкыбыз хәзинәләрен куллану- балаларның иҗади күзаллаулары арттыра, логик фикерләү сәләтен үстерә. Балаларда дуслык, гаделлек, зирәклек тәрбияләнә; тырыш, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирә; ярдәмләшү, игътибарлылык кебек матур сыйфатлар тәрбияли, кече яшьтән бала күңелендә туган төбәгенә, ана теленә, милләтенә мәхәббәт, ихтирам хисләре уята. Бүгенге балаларның белем, яхшы тәрбия алырга тулы мөмкинлекләре бар. Безгә бары тик белем алуга тырышлык, теләк һәм омтылыш тәрбияләргә кирәк. Безнең кулларда балалар язмышы. Безнең балаларыбыз бөтен яктан да үрнәк булып үссеннәр һәм милләтебез горурланырлык шәхесләр булсыннар иде. Үз телендә матур итеп сөйләшә белгән бала киләчәктә дә үз милләте белән горурланып яшәячәк.

**Кулланылган әдәбият:**


1. Гөлбакча. Балалар бакчалары өчен хрестоматия хәзинәләре. Яр Чаллы 1992 ел.
2. Раушан көзге. Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия. Казан, “Мәгәриф”,1993 ел.
3. Татар календаре. Казан 2009 ел.
4. К.В. Закирова “Күңел ачыйк бергәләп” Казан 2003 ел.
5. Иң матур сүз: ата-аналар һәм балалар бакчалары өчен хрестоматия, төзеде К.В.Закирова, - Казан:Мәгәриф 2000ел
6. Кашапова М.Ф. Иң гүзәл тел - туган тел.- Казан: РИЦ»Школа2, 2009 -202Б.
7. Закирова К.В. Уйный-уйный үсәбез: балалар бакчасында уеннар: балалар бакчасы
тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма. – Казан:Мәгәриф, 2005 175б.

А.И. Нуруллина, воспитатель,
МБДОУ «Детский сад №17»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

# Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның этномәдәни белемен формалаштыру буенча «Туган як нәрсәдән башлана?» педагогик проекты

**Проектта катнашучылар:** педагоглар, балалар бакчасы хезмәткәрләре, тәрбияләнүчеләр һәм аларның әти-әниләре.

## Аңлатма язмасы. Актуальлек

Рәсәй һәрчак күпмилләтле дәүләт булды, ә Татарстан республикасы Рәсәйнен кечкенә бер өлеше булса да, гасырлар дәвамында төрле тел төркемнәре һәм гореф-гадәтләр яшәгән халыклар белән тыгыз бәйләнештә тора.

Баланың үсеше кечкенәдән үк әхлакый патриотик һәм этномәдәни тәрбия бирүдән башка мөмкин түгел, ул кече Ватанга (туган гаиләгә, балалар бакчасына, шәһәргә, крайга) мәхәббәт тәрбияләүдән башлана, ата-бабаларның тарихын һәм мәдәниятен өйрәтеп рухи яктан бай шәхес тәрбияләү хәзерге вакытта зур эш булып тора.

Этномәдәни тәрбиянең максаты-балаларны рухи-әхлакый яктан үстерү, Идел буе халкы мәдәнияте кыйммәтләрен белеп, анлап камиллеккә омтылыш уяту.

Балаларда башка халыкларга толерантлык тәрбияләү- шулай ук педагог эшенең мөһим бурычларының берсе санала. Безнең республикада да, безнең шәһәрдә дә халык вәкилләре күп. Болар-татарлар, руслар, чувашлар, удмуртлар, мари халкы, керәшенләр һ. Б. Проект балада һәрьяклы (физик, шәхси, танып белү, рухи, эстетик) үсешне арттыруга юнәлтелә һәм милли культура, туган якны, туган (татар, рус) телне өйрәнү аша аның баетылуын күздә тота. «Милли культураны, үз халкыңның рухи байлыгын өйрәнү, аны шушы җирдә яшәгән башка халыклар культурасы белән баету, баланың культурага булган билгеләмәсе киләчәктә аңа бөтендөнья культурасын аңларга ярдәм итәчәк. Бары тик үз халкының культурасына булган шундый киң караш, аны зуррак
масштабтагы культура процесслары контекстларында кабул итү генә иҗади шәхес формалашуга һәм үсешенә нигез булып торачак, ул үз чиратында милли культураны пассив күзәтергә генә түгел, ә аңа шәхсән үз өлешен кертергә, культура барлыкка килү роцессында катнашырга мөмкинлек бирәчәк. Әлеге проект мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшнең эчтәлеген баетырга, танып белүдә, иҗат итүдә аларның ихтыяҗларын

канәгатьләндерергә, милли төбәк компоненты үсеше дәрәҗәсен тормышка ашырырга ярдәм итәр дип ышанабыз. Проект мәктәпкәчә балачакның мөһим чор икәнен күрсәтә, чөнки анда туган як тарихын, культурасын, табигатен танып белү баланың иҗтимагый уңышка

китерәчәк культура. Шул уңайдан «Туган як нәрсәдән башлана?» проектының актуаллеге нигезләнде, проект ФГОС таләпләрен нигеәләнеп язылды.«Туган як нәрсәдән башлана?»" проекты 3 елга исәпләнә.

**Проектның максаты**: Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның этномәдәни компетентлыгын формалаштыру.

**Укыту бурычлары:**

-этномәдәни белем һәм тәрбия бирү өчен нәтиҗәле методик һәм дидактик кулланма булдыру; төрле укыту формалары кулланып балаларда милли һәм төбәк мәдәниятенең төп этномәдәни кыйммәтләренә кызыксыну формалаштыру

**Тәрбияви бурычлар:**

-эстетик культураны , төрле сәнгать-иҗади эшчәнлек (декатив-гамәли, сынлы, музыкаль, сәнгатьчә-сөйләм һәм театральләштерелгән эшчәнлек һ. б.) аша матурлык хисе тәрбияләү;

-мәктәпкәчә яшьтәге балаларда поликультуралы белем бирү мөхите шартларында уңай этнотолерантлык мөнәсәбәте һәм шәхес сыйфатлары тәрбияләү;

-балаларны Татарстан республикасы (Идел буе халкының:татар, рус, чуваш, удмурт, мари, керәшен һ.б) территориясендә яшәүче халыкларының тарихы һәм мәдәнияте белән таныштыру;

рухи-әхлакый сыйфатлар булдыру һәм туган якка карата мәхәббәт тәрбияләү;

**Үстерү бурычлары:**

-татар, рус, чуваш, удмурт, мари, керэшен халыкларынын гөреф-гадәтләре нигезендә танып белү күнекмәләрен үстерү;

-мәктәпкәчә яшьтәге балаларда, ата-аналарда татар, рус, чуваш, мари, удмурт, керәшен халыкларын гөреф-гадәтләренә кызыксынуны үстерү

**Проект методлары һәм технологияләре:**

- Интерактив укыту ысулы;
- Шәхси юнәлешле технология;
- Уенлы өйрәнү технологиясе;
- Күзәтү һәм сөйләшү ысулы;

**Ата-аналарны һәм педагогларны активлаштыру ысуллары:**

- Төрле фикерләр белән алышыну;
- Гаилә тәрбиясенең проблемалы мәсьәләләрен хәл итү;
-Баланы ата-аналары һәм педагоглары тарафыннан анализлау;
- Ата-аналарның тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итү.
- Квест-уеннар үткәрү, интеллектуаль биремнәр.

**I этап әзерлек**

- проект төзү өчен методик һәм нәфис әдәбият сайлау;
-проектның максатларын һәм бурычларын билгеләү,
- эшчәнлекнең перспектив планын эшләү;
- дидактик, хәрәкәтчән, сюжетле рольләр, интерактив уеннар сайлау;
- педагогларның һәм балаларның уртак чаралар планын төзү;
- проект кысаларында ата-аналар белән хезмәттәшлек итү;
- ата-аналар өчен мәгълүмати материал сайлау;.
- “балаларга үз этнотмэдэни белем бирү нигезләрен” өйрәтү;
- тема буенча эшнең методик материалын эшләү (конспектларны эшләү, авторлык уеннары ясау, дидактик материалны баету)

**II этап – Төп этап:**

- перспектив план нигезендә проектның төп юнәлешләрен тормышка ашыру;
- этномәдәни белем бирү нигезләре буенча балаларның белем дәрәҗәсен, осталыгын һәм күнекмәләрен билгеләү өчен мониторингның диагностик инструментарийын эшләү;
- этномәдәни белем бирү нигезләре буенча балаларның белемнәрен үзләштерү мониторингы:
- балаларның этномәдәни белем бирү нигезләре буенча белем алуын характерлый торган белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләрен анализлау;
- "этномәдәни белем бирү нигезлэре һәм сөйләм теле компетенцияләрен формалаштыру” проектын тормышка ашыру.

**III этап – Йомгаклау этабы:**

- проект буенча башкарылган эшләргә йомгак ясау.
- проект буенча тормышка ашырылган эшнең нәтиҗәләрен анализлау;
- оешма, шәһәр һәм җүмһөрият дәрәҗәсендә эш тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату;
- эшләнгән методик материалны системалаштыру;
-педагогның авторлык сайтын булдыру һәм сайт битләрендә тәҗрибә куренешләре;
- тәҗрибә алмашу буенча мәкаләләр бастыру.

**Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның этномәдәни белемен формалаштыру буенча «Туган як нәрсәдән башлана?» педагогик проекы буенча перспектив план (5-6 яшьлек зурлар төркем балалары өчен)**

| **Ай** | **Тема** | **Максат** | **Балалар белән эш формалары** | **Ата-аналар белән эш формалары** |
|---|---|---|---|---|
| Октябрь | Татар милли бизәкләре | Мәктәпчә яшьтәге балаларны татар милли бизәкләре белән таныштыру | Дидактик уен “Калфакны бизә” | **Рәсем бәйгесе** “Татар халкынын милли бизэклзре” |
| Ноябрь | Татар шәгыйрләре, язучылары | Балаларны татар шәгыйрләре, язучылары белән таныштыру | **Курсәтмәле әсбаплар** кулланып татар язычулары белән | Татар язучыларынын бер **шигырен** сайлап алып балалар белән **өйрәнү** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | танышу | |
| Декабрь | Татар халык милли киемнәре | Мәктәпкәчә яшьтәге алаларны татар халык милли киемләре белән таныштыру. | Балалар бакчасындагы милли музеена экускурсия Интервью | Интервьюдан **видеоязма** күрсәтү |
| Январь | Татар халык ашлары | Балаларны татар халык милли ашлары белән таныштыру. | Сюжетлы уен “кунакны сыйла” | Татар милли ашлары **Фото-кургәзмә** |
| Февраль | Татар халык уенлары | Татар халык уеннары аша мәктәпкәчә яшьтәге бала ларга милли һәм әхлак тәрбиясе бирү. | “Тотам тотышлы” уенын оештыру | “Нинди татар халык уеннары беләсез?” **Мәгълүмат туплау** |
| Март | Татар халык әкиятләре | Балаларны әкиятләр аша матур әдәбияткә кызыксыну уяту | Әкияттә кунакта “Өч кыз” әкиятен тынлау | **Әңгәмә** оештыру. |
| Апрель | Татар халык аваз иҗаты | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларн ы халык авыз иҗаты әсәрләренә, фольклорына карата мәхәббәт уяту. | Бармак уеннары "Карга әйтә кар кар” | **Табышмаклар кичәсе** уздыру |
| Май | Татар халык милли бәйрәмләре | Балаларның татар халык йола лары, бәйрәмнәре турында белемнәрен баету | “Мини Сабантуй” тәбигатьтә куңелле чара уздыру | Ата-аналарны татар халык милли бәйрәмләре белән таныштыру максатындан **Акция** уздыру |

## Этномәдәни компетенциясе дәрәҗәсен тикшерү өчен булдырылган диагностика

## Зур төркем

***Бәяләү***

**2 балл** – *бала этномәдәни сүзләрне яхшы белә, аларның мәгънәсен аңлый;*

**1 балл**-*бала сүзләрне белә, аларның мәгънәсен һәрвакыт аңламый;*

**0 балл**-*бала этномәдәни телне белми, аңламый аларның мәгънәләре.*

| Критерияләр | Баланың фамилияәсе һәм исеме. | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |
| халык кәсепләренең кайбер предметларны материалларны, эчтәлек буенча аера; әйберләргә эзлекле карый; гомуми һәм типик билгеләрне, кайбер экспрессивлык чараларын аера | | | | | | | | | | | |
| Бала китапны кабул итү процессына җиңел кертелә, вакыйгаларга һәм геройларга | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| мөнәсәбәтен белдерә, кайбер сәнгать чараларының матурлыгын чагылдыра, геройларны, аларның тышкы кыяфәтенең үзенчәлекләрен, атый, геройларның эш-гамәлләренең ачык мотивларын аңлата | | | | | | | | | | | |
| табышмак, әкият, хикәя, шигырь, әкият кебек әдәби жанрларның кайбер үзенчәлекләре турында күзаллау бар | | | | | | | | | | | |
| поэтик әкиятләр яттан сөйли, шигъри рифмалар, кыска тасвирлау серләре уйлап таба | | | | | | | | | | | |
| Может установить связь между средствами выразительности и содержанием музыкально-художественного образа | | | | | | | | | | | |
| Музыкада эмоциональ тонны аера | | | | | | | | | | | |

## 6-7 яшьлек өлкән төркем балалары өчен каралган перспективлы план

| **Ай** | **Тема** | **Максат** | **Балалар белән эш формалары** | **Ата-аналар белән эш формалары** |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь | Рус милли бизәкләре | Мәктәпчә яшьтәге балаларны рус милли бизәкләре белән таныштыру | **Дидактик уен** “Кулмәкне бизә” | Музей өчен оештырылгын рус милли бизәкләре белән бизәлгән борынгы **кием-салым кургәзмәсе** |
| Сентябрь | Башкорт милли | Мәктәпчә яшьтәге | **Аппликация** үрнәк | Фетрдан мини |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | бизәкләре | балаларны башкорт милли бизәкләре белән таныштыру | буенча “башкорт калфагын чуклар белән бизә” | **калфак тегү** |
| Октябрь | Чуваш милли бизэклэре | Мәктәпчә яшьтәге балаларны чуваш милли бизәкләре белән таныштыру | **Интерактив уен** “чуваш милли бизэклэрен тап” | Төрле милләт бизәкләре белән танышу максатындан **буклетлар** өләшү |
| Октябрь | Рус милли ашлары | Балаларны рус халык милли ашлары белән таныштыру. | Пластилиннан **каравай әвәләу** | **Рус милли ашлары кичэсе** |
| Ноябрь | Башкорт милли ашлары | Балаларны башкорт халык милли ашлары белән таныштыру. | Башкорт милли ашлары чагылган **рәсемнәр карау** | **Викторина** уздыру |
| Ноябрь | Чуваш милли ашлары | Балаларны чуваш халык милли ашлары белән таныштыру. | Чуваш милли ашлары белән таныштыру максатындан **Кыскаметражлы видео карау** | **Тест уздыру** |
| Декабрь | Рус халык милли киемнәре | Мәктәпкәчә яшьтәге алаларны рус халык милли киемләре белән таныштыру | **Музейга сәяхәт** | **Шедеврлар бәйгесе** өчен курчакка кием тегу |
| Декабрь | Башкорт халык милли киемнәре | Мәктәпкәчә яшьтәге алаларны башкорт халык милли киемләре белән таныштыру | **Аз хәрәкәтчән уен** “Кем тизрәк киенер?” | Фетрдан **калфак ясау** |
| Январь | Чуваш халык милли киемнэре | Мәктәпкәчә яшьтәге алаларны чуваш халык милли киемләре белән таныштыру | **Дидактик уен** Төрле халык милли киемнэре арасында **“Чуваш халык милли киемнэрен сайлап ал”** | Аппликация “Чуваш халык милли кулмәге” |
| Январь | Рус халык уенлары | Рус халык уеннары аша мәктәпкәчә яшьтәге балаларга милли һәм әхлак тәрбиясе бирү. | **Хәрәкәтчән уен** “Куз бәүләү” | Иске яңа елны озату. **“Уеннар кичэсе”** |
| Февраль | Башкорт халык уенлары | Башкорт халык уеннары аша мәктәпкәчә яшьтәге балаларга милли һәм әхлак тәрбиясе бирү. | **Хәрәкәтчән уен** “урын алу” | Этилэр коне **“Аркан тарту” уены** |
| Февраль | Чуваш халык уенлары | Чуваш халык уеннары аша мәктәпкәчә яшьтәге бал аларга милли һәм әхлак тәрбиясе бирү. | **Хәрэктәчән уен “кем бу- әйт әле”** | Чуваш халык уеннары белән танышу мактасында **буклетлар тарату** |
| Март | Рус халык милли бәйрәмнәре | Балаларның рус халык бәйрәмнәре турында белемнәрен баету | рус халык милли киемнәре белән танышу максатындан **курсәтмәле әсбаплар карау** | Ата-аналар белэн берлектэ **белен бәйрәмен оештыру** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Март | Башкорт халык милли бәйрәмнәре | Балаларның башкорт халык бәйрәмнәре турында белемнәрен баету | Башкорт халык милли бәйрәмнәре чагылган **Кыскаметражлы видеофильм** карау | **Нәүрүз** бәйрәмен оештыру |
| Апрель | Чуваш халык милли бәйрәмнәре | Балаларның чуваш Халык бәйрәмнәре турында белемнәрен баету | **Видеоролик карау** | Чуваш халык милли бәйрәмнәре белән таныштыру максатыннан **буклетлар тарату** |
| Апрель | Рус халык экиятләре | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда рус халык экиятләрен карата кызыксыну уяту. | **"Өч аю"** экиятен тыңлау | "Әкиятләрнен әһэмияте" турында **әңгэмэ уздыру** |
| Май | Башкорт халык экиятләре | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда башкорт халык экиятләренә карата кызыксыну уяту. | **Камыр-Батыр экиятен тынлау** | Ата-аналар тарафыннан **театрләштерелгән экияттән өзек** |
| Май | Чуваш халык экиятләре | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда чуваш халык экиятләренә карата кызыксыну уяту. | Чуваш халык экиятләрендән чагылган **сюжетлар күргәзмәсе** оештыру | **Рәсем кургәзмәсе** Чуваш халык экиятләрендән алынган сюжетлар |

## Этномәдәни компетенциясе дәрәҗәсен тикшерү өчен булдырылган диагностика

## Мәктәпкә әзерлек төркеме

## Бәяләү

**2 балл** – *бала чиктәш халыкларның этномәдәни культуралары турындагы күзаллауларны рәсем эшчәнлегендә иҗади яктан сурәтли белә; кулдан ясалган әйберләр дөрес, матурлыгы, детальләре белән аерылып тора, төрле халык аваз иҗатларын, уенларын, бәйрәмнәрен, аш-ризыкларын һ.б. белә;*

**1 балл** – *бала чиктәш халыкларның этномәдәни культуралары турындагы күзаллауларны иҗади яктан сурәтләргә тырыша төрле халык аваз иҗатларын уенларын, бәйрәмләрен , аш-ризыкларын һ.б. истә калдырырга тырыша, ләкин педагог киңәшләренә мохтаҗ; кулдан ясалган әйберләрдә кайбер кимчелекләр ачыклана;*

**0 балл**-*баланың чиктәш халыкларның этномәдәни мәдәниятләре турындагы күзаллауларны рәсем эшчәнлегендә сурәтләү теләге юк, төрле халык аваз иҗатларын, уенларын, бәйрәмнәрен, аш-ризыкларын белми; кулдан ясалган эшләнмәләр игътибарсыз башкарылган.*

| Критерияләр | Баланын фамилиясе һәм исеме | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | | | |
| матур күренешләргә эмоциональ-эстетик яктан карый | | | | | | | | | | | | | | | |
| сәнгать төрләре буенча таныш әсәрләрне, халык һөнәрчелеге предметларын материаллардан, функциональ билгеләнештән аера һәм атый, кайбер танылган | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| әсәрләрне һәм истәлекле урыннарны таный | | | | | | | | | | | | | | | | |
| билгеле бер тема яки жанр әсәрләренә аерым бер караш таба; яраткан текстларны атый, аларны ни өчен ошатканын аңлата | | | | | | | | | | | | | | | | |
| текстларны кабатлау һәм уйлап табу процессында тел экспрессивлыгы әдәби сөйләм чараларын куллана | | | | | | | | | | | | | | | | |
| сәнгать эшчәнлегенең төрле төрләрендә, табышмаклар, әкиятләр иҗатында үзен актив һәм иҗади яктан күрсәтә | | | | | | | | | | | | | | | | |
| концертларга, музыкаль театрга, музейларга йөрү теләген белдерә | | | | | | | | | | | | | | | | |
| музыкаль эрудицияләнгән, музыка жанрлары турында фикерләре бар | | | | | | | | | | | | | | | | |
| үз иленең атамасын әйтә, аның дәүләт символларын белә, башка илләрдәге кешеләрнең тормышына кызыксыну күрсәтә | | | | | | | | | | | | | | | | |
| ул үзе һәм гаиләсе, үз теләкләре, казанышлары, кызыксынулары турында сөйли | | | | | | | | | | | | | | | | |
| гаилә тормышы белән кызыксына, тәрбиячеләргә хөрмәт күрсәтә, гаилә тормышы һәм балалар бакчасы белән кызыксына | | | | | | | | | | | | | | | | |
| женес, яшь, һөнәр (балалар, укучылар, олылар, өлкәннәр) буенча чынбарлыктагы тормышта да, иллюстрацияләрдә дә кешеләрне аера | | | | | | | | | | | | | | | | |
| узенең исемен, фамилиясен, яшен, женесен яхшы белә | | | | | | | | | | | | | | | | |
| узе яшәгән шәһәр (авыл) белән кызыксыну күрсәтә, аның истәлекле урыннары, шәһәр тормышы вакыйгалары турында кайбер | | | | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| мәгълүматларны белә | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Илебез ничек атала, аның дәүләт символларын белә, үз иле өчен горурлык хисе кичерә | | | | | | | | | | | | | | | | |
| башка илләрдәге кешеләрнең тормышына кызыксыну күрсәтә | | | | | | | | | | | | | | | | |

**Ата-аналар белән педагогик эш юнәлешләре**

Балалар бакчасы гаилә белән тыгыз элемтәдә булса, этномәдәни белем бирү һәм тәрбия формалаштыру нәтиҗәлерәк бара. Гаиләне мәктәпкәчә яшьтәге балаларны социаль мөхит белән таныштыру процессына тоташтыру зарурлыгы гаиләгә ия булган һәм мәктәпкәчә учреждениене алыштыра алмаган махсус педагогик мөмкинлекләр белән аңлатыла: балаларга мәхәббәт һәм ярату, мөнәсәбәтләрнең эмоциональ-әхлакый байлыгы. Болар барысы да этномәдәни белем һәм тәрбия бирү өчен уңайлы шартлар тудыра. Балалар бакчасы үз эшендә ата-аналарга балалар учреждениесе ярдәмчеләре буларак кына түгел, ә балалар шәхесен формалаштыруда тигез хокуклы катнашучылар буларак та таяна.

Ата аналар зур кызыксыну белән төркемнең үсеш мохитен булдыруда катнашалар:

-театральләштерелгән эшчәнлек өчен костюмнар әзерләү;

-төркем бәйрәмнәрен оештыру;

-рәсем конкурслары;

-спорт ярышлары;

-балалар өчен рус киемнәре элементларын әзерләү;

-фотокүргәзмәләр.

Әлеге бурычлар эшчәнлекнең барлык төрләрендә дә хәл ителә: өзлексез белем бирү эшчәнлегендә, уеннарда, хезмәттә, көнкүрештә һ. б. Гаилә потенциалын куллану юлы белән башкарыла:

-ата-аналарны дәресләр үткәрүгә җәлеп итү (балаларны үзләрендә булган халыкларның гореф-гадәтләре белән таныштыру, яки аларны нинди дә булса һөнәргә, этномәдәни үзенчәлекләргә өйрәтү чигү, халык музыка уен коралында уйнау);

-ата-аналарның гаилә иҗаты күргәзмәләрендә катнашуы;

-гаиләләр үзләренең гаилә традицияләре чагылгын презентацияләр;

-ата-аналарда, гаиләдә сакланган яки сәяхәттән китерелгән фотосурәтләр, альбомнар, брошюралар, көнкүреш; төркем бүлмәсендә мини гаилә коллекциясе музее булдыру;

-ата-аналар тарафыннан тәрбияче тәкъдим иткән маршрутлар буенча экскурсияләр оештыру;

Бу программаның үзенчәлеге булып олыларның үз-үзләренең тотышындагы уңай мисаллар бик зур әһәмияткә ия. Шуңа күрә педагогларга

бу очракта үзләре генә исәпкә алып калмыйча, үзара ата-аналар белән аңлашуга ирешергә, һәм бергә эшләүгә дә зур игътибар бирергә кирәк булганын анларга тиешләр.

**Көтелгән нәтиҗәләр**

-Идел буе халкы мәдәнияте узенчәлекләрен өйрәнү, аера белү;

-балаларда үз(татар) халкының мәдәни традицияләре, яшәү рәвеше, халык кәсепләре, халык һөнәрчелеге, халык һөнәрчелеге эшләнмәләре турында күзаллаулар булу;

-балаларда тарихи мираска хөрмәт формалаштыру;

-рус, татар, чуваш, мордва,удмурт, мари,керәшен халкының тарихына һәм мәдәниятенә кызыксыну тәрбияләү;

-балаларда әйләнә-тирә чынбарлыгының эстетик күренешләренә һәм сәнгатькә тотрыклы уңай кызыксыну уяту;

-балаларның төрле сынлы материаллар белән эшләү буенча практик күнекмәләргә ия булулары;

-декоратив-гамәли, сынлы, музыкаль, нәфис-сөйләм һәм театральләштерелгән эшчәнлектә иҗади күренешләр тудыру.

**Кулланылган әдәбият**


1 Алешина Н. В. Знакомство дошкольников с родным городом и страной (Патриотическое воспитание). М.: УЦ Перспектива, 2011. 145 с.

4. Алешина Н. В. Патриотическое воспитание дошкольников. Методическое пособие. М.: ЦГЛ., 2005. 150 с.

5. Андреева Н.Ф. Планирование работы по патриотическому воспитанию в ДОУ // Управление ДОУ. – 2005. – №1. – С. 21.

6. Зеленова Н. Г., Осипова Л. Е. Мы живем в России М., 2011. 156 с.

7. Шаехова.Р.Х., Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы. – РИЦ, 2012. – 208 с.

А.А.Сиразетдинова, воспитатель
МБДОУ «Детский сад №17»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

## Использование квест-игр в реализации этнокультурного компонента в работе с дошкольниками

*Ключевые слова: воспитание, этнокультурная функция, квест, загадка, приключенческая игра.*

В настоящее время большое внимание стало уделяться воспитанию на народных традициях, распространению идей этнопедагогики, приобщению детей к сокровищам народных культур с целью возрождения, сохранения и развития неиссякаемого источника мудрости и исторического опыта народа, формирования национального самосознания детей и юношества — достойных представителей своего этноса, носителей своей национальной культуры.

В наше сегодняшнее время нельзя забывать о народности и национальном характере образования, который является одним из главных принципов его развития. К. Ушинский писал: «Воспитание, если оно не хочет быть бессильным, должно быть народным…» «Воспитание, созданное самим народом, основанное на народных началах, имеет ту воспитательную силу, которой нет в самых лучших системах, основанных на абстрактных идеях…».

На современном этапе одной из важных задач образовательных учреждений становится восстановление их этнокультурной функции. В дошкольных учреждениях предусматривается освоение национально-регионального компонента как составной части содержания образования, направленного на ознакомление всех детей с основами этнической культуры коренного населения и на этой основе воспитание толерантности, формирование межкультурной коммуникации.

Этнокультурная компетентность дошкольника – формирующееся личностное качество, развитие которого осуществляется последовательно. От познания своей национальной культуры, понимания и принятия этнокультурных различий – к убеждению, что этнокультурное многообразие – это позитивное, прогрессивное явление, и затем к выстраиванию положительного взаимодействия с другими людьми.

Методы и приемы активизации процесса формирования этнокультурной осведомленности детей:

1. Игровые методы и приемы вызывают у детей повышенный интерес и положительные эмоции, содействуют концентрации внимания на учебной задаче, которая становится не навязанной, а своей личной целью.
2. Метод воображаемых ситуаций (местом, ролями, оборудованием, действиями) повышает степень усвоения познавательного материала.

3. Метод сюрпризный момент способствует активизации эмоциональности детей.

4. Словесный метод. Ценным приемом, является сравнение, позволяющее выявлять общее и особенное в историческом развитии и культурах разных народов, причины этих сходств и различий.

5. Метод моделирования и конструирования, сочетающий словесное объяснение, практическую реализацию и игровую мотивацию.
6. Метод проектов, предполагает организацию совместной исследовательской деятельности детей и их родителей в сборе изучении, анализе, а затем презентации материалов, которые раскрывают особенности традиций, образа жизни, предметов быта, искусства народа.

7. Одним из современных методов этнокультурного воспитания дошкольников является квест-игра.

Квест-игры одно из интересных средств, направленных на самовоспитание и саморазвитие ребёнка как личности творческой, физически здоровой, сактивной познавательной позицией. Что и является основным требованием ФГОС.

Квест - это приключенческая игра, в которой необходимо решать задачи для продвижения по сюжету. Суть в том, что, как правило, есть некая цель, дойти до которой можно только последовательно разгадывая загадки. Каждая загадка - это ключ к следующей точке и следующей задаче. А задачи могут быть самыми разными: активными, творческими, интеллектуальными. Они подбираются таким образом, чтобы быть максимально оригинальными, интересными, соответствующими ситуации и не требующими специальных знаний или умений от игроков. Замечательно то, что квесты могут проводиться как в группе, в музыкальном зале, так и на природе, то есть практически в любой обстановке.

Квест - игры помогают нам активизировать детей. Это игра, в которой задействуется одновременно и интеллект участников, их физические способности, воображение и творчество. Здесь необходимо проявить и смекалку, и наблюдательность, и находчивость, и сообразительность, эта тренировка памяти и внимания, это развитие аналитических способностей и коммуникативных качеств. Участники учатся договариваться друг с другом, распределять обязанности, действовать вместе, переживать друг за друга, помогать. Все это способствует сплочению детского коллектива.

**Список использованной литературы**

1. Соломенникова О.А. Радость творчества. Ознакомление детей 5-7 лет народным искусством. М.: Мозаика-Синтез, 2005

А.М. Гибадуллина, воспитатель
МБДОУ «Детский сад №1»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

**«Хикмәтле дә, бизәкле дә, әнкәм биргән туган тел!» исемле проект**

*Төп сүзләр: хикмәтле дә, бизәкле дә әнкәм биргән туган тел; Мәгариф турындагы закон; Татарстан Республикасының суверенлыгы турындагы Декларация; гомумкешелек кыйммәтләре; инновацион педагогик технологияләр; мәдәни - белем бирү тирәлеге; федераль дәүләт белем бирү стандарты; этномәдәни халәт; социаль ихтыяҗ; мәдәни - белем бирү мохиты; эмоциональ компонент; милли тирәлек; күңел байлыгы; мәдәни мирас; алтын хәзинә.*

Милләтеңне, телең, динең сатсаң,
Бездән калыр бары таш исем.
Тарихлардан төшеп калмыйк, дисәң,
Бу дөньда шундый итеп яшә –
Башка милләт сиңа хөрмәт белән
Бу – татар бит диеп баш исен.
*Флёра Тарханова*

Татарстан Республикасының «Мәгариф турында»гы Законы, гомумкешелек кыйммәтләре өстенлеген истә тотып, «милли белем бирү учреждениеләренең эшчәнлеге шәхеснең милли үзаңын яңартуга юнәлтелгән» дип билгели. Бу бурычны тормышка ашыру гаиләдә үк башлана һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларга ана телендә тәрбия һәм белем бирү өчен мөмкинлекләр тудыру, халкыбызның рухи байлыгына. мәдәниятенә якынайту шартларында алып барыла.[9]

Татарстан Республикасының суверенлыгы турындагы Декларация һәм татар теленең рус теле белән беррәттән, дәүләт теле буларак кабул ителүе балаларга белем һәм тәрбия бирү эшендә тамырдан үзгәрешләр кертте. Кешенең кыйммәтен аңларга, аның хезмәтенә ихтирам белән карарга, шәхеснең көченә һәм акылына ышанырга, хөррияттә генә нык үсешкә ия булуына инанырга өйрәтү бүгенге тәрбия эшенең төп кануны булып тора. Әнә шул таләпне үтәү йөзеннән балалар бакчаларында халык традицияләреннән файдаланып, милли бәйрәмнәребезне үткәрүгә зур әһәмият бирелә.

Соңгы елларда балалар бакчаларында татар халкының гореф – гадәтләрен, йолаларын өйрәтүгә һәм милли бәйрәмнәрне үткәрүгә игътибар арта бара. Аларны халыкчанрак, җанлырак итүгә, яңартып, тергезеп,

көнкүрешебезгә кайтаруга омтылыш көчәя. [7]

Билгеле булганча, халыкның гореф – гадәтләре, мәдәнияте юкка чыга икән, бу аның рухи байлыкларының саега баруын чагылдыра. Тарих инде исбатланган: әгәр бер милләт башка бер милләт эчендә үзенең үзенчәлекләрен югалта башласа, бу милләт, һичшиксез юкка чыгачак. Халык тарафыннан кертелгән гореф – гадәтләр – шул халыкны милләт итеп берләштерә торган чараларның берсе. Алар халыкның милли горурлыгын, милли аңын, хисләрен, рухын, көчен тәрбияләргә, формалаштырырга ярдәм итеп кенә калмый, ә шул хисләрне кичергән кешеләрдә рухи канәгатьләнү тудыра. Баланы тәрбияләү иң элек тәрбиячenең, олы кешенең үз-үзен тәрбияләвеннән башлана. Педагогик белемнәребезне туктаусыз, даими рәвештә тирәнәйтү, тулыландырып тору, югары культуралыкка омтылу, үзеңне кешеләр белән дөрес аралаша белергә күнектерү, үзебез һәм балаларыбыз яши торган чиксез киң дөньяга игътибарлы булырга өйрәнү менә ни өчен кирәк икән![3]

Кеше җиргә бер генә килә. Аның хыяллары, тормышы бай кылган эшләре матур, башкаларга үрнәк булып калырлык булсын. Халкыбызның күңел бизәкләрен хәзер яшь буын үстерергә, яшәртергә, тагын да баетырга тиеш. Гасырлардан гасырларга күчеп, безнең көннәргә килеп җиткән милли гүзәллекне алдагы буыннарга мирас итеп җиткерү эше балаларга тапшырыла.

Балалар бакчасының татар төркемендә эшләү дәверендә ана телебезнең нинди күркәм, нинди гүзәл, затлы, асыл булуына төшендем.Балаларга туган телебезнең бай мираслы,тирән тарихлы булуын күрсәтү өчен бик күп чаралар даими үткәрелеп тора. Без үзебезнең балалар бакчасында халкыбызның яраткан бәйрәмнәрен, күркәм йолаларын даими үткәреп барабыз («Сөмбелә», «Аулак өй», «Кышкы кич утырулар», «Каз өмәсе», «Нәүрүз», «Сабан туе», «Кунак төшерү» һ.б.) Бу бәйрәмнәрне, кичәләрне уздырганда ата – аналарны да катнаштырырга тырышабыз. Алар белән төрле конкурслар, акцияләр, мастер-класслар, фото-күргәзмәләр («Безнең гаиләнең яраткан ризыгы», «Мин яшәгән шәһәр яки авыл», «Нәсел шәҗәрәсе», «Ата аналар белән бер көн», «Гаиләнең яраткан бәйрәме», «Туган тел атналыгы»; һ.б.) оештырабыз.[2]

Шулай ук программада каралган көндәлек иҗтимагый бәйрәмнәрне дә («Белем көне», «Әниләр көне», «Яңа ел», «Абдулла Алиш әкиятләре», «Әтиләр бәйрәме», «8 нче март», «Габдулла Тукай – безнең күңелләрдә», «Җылы яктан безне сагынып канатлы дусларыбыз кайтты», «Җиңү көне», «Хуш, күңелле бакчабыз», «Балаларны яклау көне»; һ.б.) һәм ана телендә башка темаларга багышланган төрле кызыклы чараларны да, кичәләрне дә халкыбызның гасырлардан килгән җор теле тудырган иҗат җәүһәрләрен, хәзинәсен – балалар фольклорын кулланып, балалар күңелендә мәңге саклanырлык итеп уздырабыз. Бары тик әти-әниләр белән бергәләп эшләгәндә генә уңышлы нәтиҗәләргә ирешеп була.Менә шунсы куандыра,күңелдә өмет чаткылары уята-балалар иркен матур итеп татарча

сөйләшәләр,аралашалар.[6]

Быел Татарстан Республикасы җирлегендә яшәүче халыкларның туган телен саклау һәм үстерүгә юнәлтелгән, туган телдә тәрбия һәм белем бирүне гамәлгә кертүче проектны тормышка ашыру буенча педагоглар арасында үткәрелә торган республика күләмендәге конкурста «Хикмәтле дә, бизәкле дә, энкәм биргән туган тел!» исемле проект белән катнаштым.[7]

Проект балаларны ана теле - татар телендә сөйләшергә өйрәтүнең тотнаклы нигезен, ана теленә өйрәтү буенча 4 компонентны эченә алган тәрбия - белем бирү процессын оештыру алымы белән татар халкының сөйләм теле һәм мәдәни байлыгын саклау максатыннан татар телен өйрәнүне формалаштыруга юнәлтелгән:

- сөйләм теле тирәлеге (балалар белән тәрбия-белем бирү эшчәнлеген ана теле-татар телендә аралашуны һәм оештыруны гамәлгә ашыру)

- әйләнә-тирә мохиты (бүлмә китапханәсен һәм музей педагогикасын булдырып, балаларны татар халкының мәдәни байлыклары турында мәгълүмат һәм көнкүреш әйберләре белән җәлеп итү)

-вакыйгалар мохиты (балаларны татар халкының йолаларын, гореф - гадәтләрен, мәдәниятен күрсәтүче мохит атмосферасына җәлеп итү)

- белем бирү процессында барлык катнашучыларының актив үзара хезмәттәшлеген гамәлгә ашыру (ата - аналарны һәм социум вәкилләрен проектта катнашырга этәрү) .[3]

Проектның уңышка ирешүенең төп сәбәпләренең берсе булып, эш барышында инновацион педагогик технологияләр (ТРИЗ, мнемотехника һәм эйдетика, буккроссинг алымнары), шулай ук цифрлы белем бирү чыганакларын кулланып, белем бирү процессында катнашучылар танып белү - тикшерү һәм мәдәни - агарту эшчәнлегенә җәлеп ителәчәк.

Балалар белән эшне оештыруның төп формасы булып, эшчәнлек алымын кулланып, татар халкының йолалары, мәдәнияте, тарихы, теле турында методик яктан материаллар белән тулыланган мәдәни - белем бирү тирәлегенә балалар кызыксынып кереп китәчәк.

Проектның төп методик нигезе булып, кызыксыну һәм танып белү ихтыяҗын күрсәтү кешенең эшчәнлек максатын булдырырга төп юнәлешен тәэмин итә, шул ук вакытта яңа күренеш белән танышырга һәм яңа белемнәрдә ориентлашырга булыша, бу үз чиратында чынбарлыкны чагылдырырга һәм үз эшчәнлеген планлаштырырга мөмкинлек тудыра.

Гаилә ул - баланы тәрбияләү нигезе-дигән нигезләмәдән чыгып, татар халкының мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре, тарихы, ана теле-татар теленең үсешен саклауга ата-аналарның кызыксынучанлыгын хуплау мәсьәләсенә проектта бик әһәмиятле урын бирелгән. Белем бирү учреждениесендә дә, шулай ук гаилә шартларында да, ата-аналар балалары белән ана теле - татар телендә актив һәм иркен аралашсыннар өчен бу юнәлештәге эш шуңа хисапланган.

Проектның максаты – мәктәпкәчә яшьтәге балаларның ана теле - татар

телендә сөйләшү һәм аралашу кызыксынучанлыгын, теләген һәм тотнаклы нигезен формалаштыру.

Проектның мәсьәләләре :

1. Балаларны ана телендә тәрбияләү һәм белем бирүне оештыру моделен (үрнәген, өлгесен) 4 компонент аша булдыру:

- сөйләм теле тирәлеген (балалар белән тәрбия-белем бирү эшчәнлеген ана теле-татар телендә аралашуны һәм оештыруны гамәлгә ашыру);

- әйләнә-тирә мохитны (татар халык мәдәни байлыклары турында күрсәтмә әйберләр һәм мәгълүмат белән балаларны тәэмин итү, музей педагогикасы);

- вакыйгалар мохиты (балаларны татар халкының йолаларын, гореф - гадәтләрен, мәдәниятен күрсәтүче мохит атмосферасына җәлеп итү).

2. Проектны тормышка ашыру буенча белем бирү процессы барлык катнашучыларының татар телен өйрәнүгә кызыксынучанлыгын уяту максатыннан чараларның календарь планын эшләү.

3. Белем бирү процессы барлык катнашучыларының тәрбия-белем бирү практикасына сөйләм теленең уңышлы үсешенә ярдәм итүче инновацион алымнар кертү.

4. Белем бирү процессы барлык катнашучыларының актив үзара бердәмлеген тормышка ашыруны тәэмин итү.

Проект 3 елга исәпләнгән. Проектның эчтәлеге календарь планны тормышка ашыру аша үтәлә. Проектның календарь планында чараларның исемнәре, максатлы аудитория, үткәрү дәрәҗәсе һәм үткәрү вакыты күрсәтелгән.

Проектны тормышка ашыруның әһәмияте һәм нәтиҗәле нигезләмәсе мәктәпкәчә яшьтәге белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартының төп кагыйдәләрендә дәлилләнә, белем бирү процессы катнашучылары белән формалашкан программаның бер өлеше «милли,социаль мәдәни һәм башка шартларның үзенчәлеген белем бирү эшчәнлегендә тормышка ашыруга»,шулай ук «...балаларның этномәдәни халәтенең үсешен исәпкә алып»ориентлашырга мөмкин булуы билгеләнә.

Үсеп килүче яшь буынның этномәдәни белем бирү әһәмияте «Белем бирү» федераль милли проектының эчтәлегендә чагыла. Татарстан Республикасында бу юнәлешне тормышка ашыру өчен дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау,өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасы эшләп килә. Бу шартларда мәктәпкәчә белем бирү системасының төп мәсьәләсе булып, балаларга туган телендә, үз халкының милли йолалары рухында белем бирүгә халык ихтыяҗын тулырак канәгатьләндерү тора.

Туган татар телендә төркемнәрнең эшләп торуы шартларында, балаларның ана теле-татар телен үзләштерүнең социаль ихтыяҗы канәгатьләндереләчәк.

Ана теле татар телен өйрәнү, саклау һәм үстерү буенча эш тәҗрибәсе өч ел эчендә уртанчылар төркеменнән башлап мәктәпкә әзерлек төркеменә

кадәр мәдәни - белем бирү мохиты үрнәген булдыру буенча тәрбия-белем бирү эшчәнлеген оештыруны үз эченә ала.

1 нче ел – уртанчылар төркеме балалары белән эшне оештыру

Максат:ана теле татар телендә сөйләм теленең модулен (үрнәген) практик кулланып, балаларның сөйләм теле активлыгын формалаштыру

2 нче ел – зурлар төркеме балалары белән эшне оештыру

Максат:инновацион технологияләр (ТРИЗ, эйдетика, мнемотехника, цифрлы технологияләр) һәм эшчәнлек алымын кулланып,балаларның ана теле татар телендә мөстәкыйль сөйләм телен активлаштыру

3 нче ел – мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән эшне оештыру

Максат:ана теле татар телендә когнитив, үз-үзен тотышы, эмоциональ компонент формасында балаларның кызыксынучанлыгын, теләген һәм тотнаклы сөйләшү һәм аралашу нигезен формалаштыру

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга ана теле татар телен өйрәтүдә тәрбия-белем бирү эшчәнлеген оештыруның моделен (үрнәген)булдыру проектны тормышка ашыруның нәтиҗәсе дигән искәрмәдән чыгып,проектның түбәндәге көтелгән нәтиҗәләре билгеләнде.

Проектның көтелгән сыйфатлы нәтиҗәләре

-3 компонент формасында ана теле-татар телендә аралашырга өйрәтүдә балаларның кызыксынучанлыгы,теләге һәм тотнаклы нигезе формалашуы: когнитивлы (татар телен белү); үз-үзен тотышы ( татар телен аралашканда куллану); эмоциональ (ана теле татар телендә арлашудан канәгатьлек хисе алу);

- татар халкының мәдәниятен, йолаларын, телен өйрәнү һәм саклау буенча бүлмә тирәлегендә банк төрендә методик материаллар белән яңалык кертү,белем бирү эшчәнлеге урыннарын актырту һәм тулыландыру (китапханә, туган як почмагы, мини – музей);

-этномәдәни, сөйләм телен өйрәтү һәм тәрбияләү буенча чараларны оештыру һәм үткәрү;

-белем бирү эшчәнлегендә барлык катнашучыларның проектны тормышка ашыру кысаларында методик чараларда актив катнашуы.

Проектның көтелгән күләмле нәтиҗәләре:

-барлык белем бирү өлкәләре буенча хәзерге заман белем бирү технологияләрен кулланып, ана теле татар теленә өйрәтү һәм тәрбияләүне оештыруда перспектив планнар булдыру (ТРИЗ, эйдетика, мнемотехника алымнары, цифрлы технологияләр, буккроссинг)

-ана теле татар телендә бүлмәнең матур әдәбият китапханәсен булдыру

-«Татар халкының көнкүреш үзенчәлекләре» мини-музееен булдыру

-календар һәм вакыйгалы чараларны оештыру буенча методик чараларның план-конспектын булдыру

-ата - аналар һәм социаль партнерлар белән үзара бәйләнешне оештыру буенча методик чараларның план-конспектын булдыру

Бу проект ана тете-татар телен өйрәнүгә,бай мирасыбызны яшь буынга

тапшыру алымнарына зур этәргеч җирә.Мин ышанам,нәниләребез туган телен яратып,аны хөрмәт итеп үсәрләр.[6]

Балачактан ук бала милли тирәлектә яши, “ана сөте“ белән мәдәни хәзинәләрне һәм әхлакый сыйфатларны сеңдерә. Үсә төшкәч, ул үз халкының Кешесе, гореф – гадәтләренең дәвамчысы һәм саклаучысы булып тора. Баланы мәдәни мираска, халыкның күңел байлыгына тартып, туган телне саклау мөһим булып тора. [8]

«Балалар – безнең киләчәгебез», дибез. Киләчәгебезне гүзәл, аһәңле итеп күрәсебез килә икән, халкыбызның телен, гореф-гадәтен, мәдәниятен, йолаларын ихтирам итүче шәхес тәрбиялик! Балаларыбызны үз үрнәгебездә тәрбияләп калырга тырышыйк. Алдагы көннәрдә алар бу алтын хәзинәне буыннан буынга тапшырсын, мирас итеп калдырсын. Үз телен, үз динен, үз халкын беркайчан да, беркая да онытмасын иде нәсел дәвамчыларыбыз! [4]

Туган тел турындагы фикерләремне шагыйрь И.Гыйләҗев сүзләре белән йомгаклыйсым килә:

Ул булганда адашмабыз
Юлым туры, нурлы көнем
Күз карасы кебек саклыйм
Анам теле – Татар телен!

**Кулланылган әдәбият исемлеге**

1 К.В.Закирова, Р.А.Борһанова.Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы. Казан:Н.Хәтер,2000.
2. К.В.Закирова,С.М.Гаффарова.«Әткәм-әнкәмнең теле.Казан:Н.Мәгариф,1997.
3. И.Ш.Нәбиуллина.«Балаларны туган якның тарихы белән таныштыру».Казан: Татарстан китап нәшрияте,2021.
4. И.МХәмитов,Г.Г. Зиатдинова.«Халык чишмәсеннән су эчәм». Яр Чаллы., 2017.
5. Нурзия«Татар сынлы сәнгате»Казан:Татарстан китап нәшрияте,1999.
6. Р.Ягъфаров.«Балалар фольклоры». Казан, Раннур нәшрияте, 1977.
7. Сафиуллина Ф.С., Ибраһимов Г.Б. Хикмәтле дә , бизәкле дә туган тел: Гомуми урта белем мәктәпләре, балалар бакчалары өчен тел турында кызыклы материаллар. – Казан: Мәгариф, 2018.
8. Ә.К.Кәримуллин.Тел – милләтнең сакчысы.- Казан: Татар. Кит.нәшр., 1997.
9. «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законы - Казан:Н.РИЦ«Школа»,1998.
10. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казань. Татарское книжное издательство.1987.

Г. А. Ахмерова, воспитатель
МБДОУ«Детский сад №3»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

**Тәрбиячеләр белән берлектә: Татар хатын-кызларынын милли бизәнү әйбере – брошка диеп исемләнгән мастер-класс.**

*Төп сүзләр:бизәк(орнамент), милли бизәнү әйберләре, чәчәкле үсемлек, брошка, алка, беләзек, чулпы, хәситә, ләлә чәчәге.*

**Мастер класс өчен җиһазлар**: ак, кызыл, яшел, зәңгәр төстәге фетр, җилем(клей момент кристал), җилем өчен пумалалар, бизәү өчен ясалма төсле (пыяла) ташлар, каптырма, кайчы, тукыма кисәкләре, алдан киселгән ләлә чәчәкләре, өлгеләре.

Мастер-класс барышы:

Хаерле иртәләр, хөрмәтле кунаклар.
Татар хатын – кызының кулыннан һичбервакыт эш төшмәгән: җеп эрләгән, шәл бәйләгән, ашъяулык,сөлге чиккән, оек бәйләгән, келәм – палас тукыган.
Халкыбызның милли бизәкләре турында сөйләшербез. Милли, бизәк төшенчәсен ничек аңлыйсыз?*(Җаваплар)*
Бизәк(орнамент) латин теленнән килеп чыккан.
Татар хатын-кызларының милли бизәнү әйберләренә тукталып үтик.
Хәзерге вакыттагы кебек үк элек тә татар хатын-кызлары бизәнү әйберләрен яратып кулланганнар. Бизәнү әйберләрен хатын-кызлар гына түгел, ир-егетләр дә киеп йөргәннәр. Ләкин хәзерге заман бизәнү әйберләре элеккеләреннән бик нык аерыла. Татар хатын-кызларының яраткан бизәнү әйберләре алка, хәситә, чулпылар булса, ир-егетләрнең – зур кашлы йөзек булган. Күргәнебезчә, хатын-кызларның бизәнү әйберләре төрле-төрле булган. Мөселман гореф-гадәтләре буенча хатын-кызның бизәнү әйберләренә карап, аның иренең байлыгы турында фикер йөртергә мөмкин булган.
Чулпы
Татар хатын-кызының төп бизәнү әйбере булып чулпылар саналган. Алар төрле формада булган һәм төрле материалдан эшләнгән. Чулпы – төрле яшьтәге татар хатын-кызлары яратып куллана торган бизәнү әйбере. Аны яшүсмер чактан ук тага башлаганнар. Эре көмеш акчалардан торган чулпыларны билдән астарак төшеп торырлык итеп чәч толымнарына бәйли торган булганнар. Ике якка үреп салып, чулпылар таккан озын чәч толымнары татар кызларының горурлыгы булган. Шунысы кызганыч, чулпылар бөтенләй кулланылыштан төшеп калган. Аларны музейларда экспонат буларак кына күрергә мөмкин.
Алкалар
Тагын да борынгырак бизәнү әйбере – алкалар. Аларны өч-дүрт яшьтән башлап олы яшькә җиткәнче киеп йөргәннәр. Озын алкалар татар халык

киеменең аерылгысыз өлешен алып торган.
Хәситә
Татар хатын-кызлары муен-күкрәк бизәнү әйбеләрен иркен кулланганнар. Алар бизәнү әйбере генә түгел, киемнең бер өлеше булып торган. Шулай ук, иң киң таралган бизәнү әйбере булып хәситә санала. Хәзерге заманда бу сүз кулланылыштан төшеп калса да, аны икенче атама белән – муенса дип атап йөртәләр.
Беләзек
Татар хатын кызлары ике кулына да беләзекләр киергә яратканнар. Беләзекләр көмеш, бакыр һәм сирәк кенә алтыннан ясалган, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән булган.
Брошка
Татар халкының декоратив сәнгатендә чәчәкле үсемлек орнаменты урын алып тора. Иң еш сурәтләнә торганы лалә чәчәге.
Менә бүген без сезнең белән ләлә чәчәге бизәгеннән брошка бизәп карарбыз.
Әлеге брошканы түшкә кулмәк, кофталарга кадыйлар.
Брошканы бай татар хатын-кызлары гына ала алганнар, чөнки алар кыйммәтле ташлардан ясалган булган.
Хәзер хөрмәтле коллегалар бергәләп брошка ясарбыз.Сезнең алдыгызда төрле төстәге фетрлар, үзегезгә ошаган төсне алып өлгене кулланып ләлә чәчәген кисеп алабыз.
Өстәлдә төрле төстәге бизәкләр, шул бизәкләрне кулланып ләлә чәчәгендә композиция төзибез.Аннары җилем (клей) кулланып ябыштырабыз.Ләлә чәчәгендә бизәкләр ябышсын өчен тукыма кисәге белән бизәкләргә баскалап чыгабыз.Брошканың арткы ягына каптырманы ябыштырабыз, нык торсын өчен фитрдан брошка төсендә тасма кисеп алып, шул тасманы ябыштырабыз.
Безнең брошкалар әзер.Һәрберебезнең брошкалары үзенчәлекле, берберсенә охшамаган килеп чыкты.Бу брошкаларны киләчәктә кулланырсыз дип ышанып калабыз. Эшегездә сезгә уңышлар теләп калабыз.Мастер класста катнашуыгыз өчен рәхмәт.

**Кулланылган әдәбият:**

1.Абдулатипов Р.Г. Мой татарский народ.- М.: Классикс Стиль, 2005.- 208с.
2.Завьялова М.К. Татарский костюм. - Казань: Издательство «ЗАМАН», - 1996.-256с.
3.История и культура родного края // Сост. Мифтахов Б.М., Исламов Ф.Ф. - Казань: Магариф, 1994.- 191с.
4.О мусульманской культуре и искусстве татар статьи автора см.: Мусульманская культура Среднего Поволжья и Приуралья: истоки и перспективы // Ислам и проблемы межцивилизационных взаимодействий. - М., 1994.-С.66-77; Мусульманская культура и изображение человека в

татарском искусстве // Иман нуры. Ислам журналы.1996, №4.-С.55-61;
5. Татарское декоративное искусство в системе мусульманской культуры //Ислам в Поволжье: история и проблемы изучения. -Казань, 2000.-С.159-170; The Islamic Culture of the Middle Volga region: roots and perspectives // Tatarstan: past and present. SOAS. -London,1992- P.17-25; Arabic Epigraphy in Tatar Decorative Arts // Islamic Art Resources in Central and Eastern and Central Europe. Al-al -Bayt University. Jordan. 1421 A.H./ 2000 A.D.
6. Казаков Е.П. Что написано на перстне? // Казан Утлары, №6, 1983 3.
7. Такое мнение было первоначально было высказано Г.В.Юсуповым:
8. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику.- М.-Л., 1960.-С.44 4. Артамонов М.И. История хазар.- Л., 1962.-С 223;
9. Смирнов А.П. Волжские булгары.- М., 1951.-С.38
10 Ковалевский А.П. Книга Ахмеда Ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу в 921-922 гг. - Харьков, 1956.-С.138
11. Фахрутдинов Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. - М., 1984.
12. Артамонов М.И. История хазар.-С. 372.
13. Большаков О.Г. Ислам и изобразительное искусство // Труды Государственного Эрмитажа. - Л., 1969.-Т.10.-С.142

Л.Г.Мирсайзянова, воспитатель по обучению
детей татарскому языку
МБДОУ«Детский сад №3»
Чистопольского муниципального района Республики Татарстан
*Ключевые слова:команда,флаги,фишки,найди пару,национальная одежда.*
Дошкольный возраст - важнейший период становления личности, в течении которого формируются предпосылки гражданских качеств, представление о человеке, обществе и культуре. Работу по реализации этно -региональной составляющей начали с обогащения предметно пространственной развивающей среды. Педагогами собран и оформлен материал в данном направлении. Это альбомы о народах Поволжья, презентации, сказки, игры. Сегодня вашему вниманию предлагаем мнемо игру «Найди пару».

Описание игры: игра состоит из яблока на стойке, в которой размещены 16 фишек. На них изображены куклы народов Поволжья парами, мальчик и девочка. Заранее рассматриваем кукол, отмечаем, что куклы одной национальности с флагами своих республик.А также есть 2 фишки со звёздами, для динамической паузы.

Цель игры: найти пару кукол определенной национальности, назвать их, определить флаги данных республик.

Ход игры: Игроки по очереди берут по 2 фишки, если они совпадают, то игрок их складывает в корзину своей команды, если нет, возвращает на место. Задача игроков, запомнить расположение фишек, постараться найти пару быстрее. Выигрывает команда, набравшая наибольшее количество фишек. Во время игры дети запоминают названия народов Поволжья, национальную одежду, флаги республик.




Список литературы:
1. Воспитание и обучение в детском саду. К.В.Закирова-Казань-2009. Шаехова Р.К.
2. Радость познания: региональная программа дошкольного образования.Казан:Магариф-Вакыт, 2016.
3. «На поляне детства» Хрестоматия для воспитателей ДОУ и родителей.-Казань:РИЦ, 2011.